

# Мәрҗани китапханәсе

Татарстан Республикасының
Милли китапханәсе

Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге

# Мәрҗани китапханәсе

Фәнни-библиографик җыентык

Казан
«Милли китап» нәшрияты
2004

ББК 78.34(2)+63.3(2Рос=Тат)+91.9
М 90

Төзүчесе һәм басмага әзерләүче
Р.Ф. Мәрданов

Җаваплы мөхәррире
И.Г. Һадиев

М 90 **Мәрҗани китапханәсе: фәнни-библиографик җыентык**/ Төз. Мәрданов Р.Ф. - Казан: Милли китап, 2004. - 122 б.

ISBN 5-88473-031-4

Җыентыкта мәшһүр татар галиме Шиһабеддин Мәрҗани (1818-1889) шәхси китапханәсенең катлаулы язмышына багышланган махсус гыйльми мәкалә, галим милкендә булган китапларның бер өлешен чагылдыра торган библиографик исемлек урын алды. Шулай ук Ш. Мәрҗани китапханәсе турындагы С. Вахиди, Ш. Шәрәф мәкаләләре һ.б. материаллар туплап бирелде.

ББК 78.34(2)+63.3(2Рос=Тат)+91.9

ISBN 5-88473-031-4

© Мәрданов Р.Ф., 2004;
© «Милли китап» нәшрияты, 2004.

## Шиһабеддин Мәрҗанинең шәхси китапханәсе

Шиһабеддин Бәһаведдин улы Мәрҗани (1818 – 1889) – атаклы татар тарихчысы, ислам дине галиме һәм мәгърифәтче. Ул – татар халкының XIX гасырдагы уяну һәм яңарыш дәверенең бөек вәкиле. Ш. Мәрҗани Казан артындагы Ябынчы авылында дөньяга килә. Ташкичү авылында әтисе Бәһаведдин мәдрәсәсендә белем алганнан соң Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укый. Казанга кайтып имамлык итә, мәдрәсә оештыра һәм җәмәгать эшләрендә катнаша. Төрки-татар тарихына караган һәм дини-фәлсәфи хезмәтләр иҗат итә. Аның тарафыннан барлыгы утыздан артык гыйльми хезмәт язылган.

Шиһабеддин Мәрҗани кечкенәдән үк укуга һәм китапка бик һәвәсле булган. Бохарада гыйлем эстәгән елларында кыйммәтле тарихи һәм дини-фәлсәфи әсәрләр туплап, үз китапханәсенә куша барган. Кайбер мәгълүматларга караганда, Мәрҗани Бохарадан берничә дөя йөге китап алып кайткан[1]. Мәрҗаниләр нәселенең борынгы кульязмалардан гыйбарәт бай китапханәләре дә аңа ата-бабаларыннан мирас булып калган. Ул Бохарадан Казанга кайтып тормыш итә башлагач та, мәдрәсәсенә һәм үзенең шәхси китапханәсенә борынгы әсәрләрне, чыгып килгән басма китапларны туплый барган. Нәтиҗәдә, Мәрҗани китапханәсе искиткеч бай китап тупламы хасил иткән.

Бөек галимнең китапханәсе, үз васыяте буенча, балаларына мирас булып калган[2]. Галимнең вафатыннан соң китапханәсе улы Борһанеддин (1855-1916), кызлары Галия (1852-1925) һәм Хауа (1870-1945) арасында бүленгән. Мирас бүлү күренекле дин галиме Галимҗан Баруди җитәкчелегендә башкарылган[3].

[1] Рәми И., Даутов Р. Әдәби сүзлек: Элекке татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек. - Казан: Татар. китап нәшр., 2001. - Б. 170.
[2] Мәрҗани: Виладәтенә йөз ел тулу мөнәсәбәте илә. - Казан: Мәгариф, 1915. - Б. 136.
[3] Ахметзянов М. Фонд Шигабутдина Марджани в Институте языка, литературы и истории им. Г. Ибрагимова // Марджани: ученый, мыслитель, просветитель. - Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. - С. 184.

Бай китапханәгә ия булган Г. Барудига да Мәрҗани китапханәсеннән өлеш чыккан. Аның карамагындагы Мәрҗани кульъязмалары, Барудиның кыйммәтле китапханәсе белән бергә, 1920 елда Татарстан хөкүмәтенә тапшырылганнар[1]. Соңрак, 1930 елларда, Барудиның бу коллекциясе Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсе фондына кергән[2].

Мәрҗанинең үз васыяте буенча өчкә бүленгән китапханәсенең язмышы бик катлаулы һәм хәзергәчә тулаем ачыкланып бетмәгән иде. Бу мәсьәләдә кайбер табышларыбыз, фикер һәм фаразларыбызны игътибарыгызга тәкъдим итәбез.

Олуг галимнең бай китапханәсе XX йөз башында ук җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә булган. Әдип Фатыйх Әмирхан 1913 елгы бер мәкаләсендә Мәрҗани китапханәсенең «...үзенең вафатыннан соң хәрабә хәлендә тәртипсез вә саклаусыз торганлыгы» турында 1910 еллар башында татар вакытлы матбугатында борчулы язмалар булганлыгын искәртә[3]. Татар мәдәни җәмәгатьчелеге Мәрҗани китапханәсе турындагы беренче киң мәгълүматны 1915 елда дөнья күргән «Мәрҗани» исемле җыентыктагы мәкаләләр аша ала. Аннан соң берникадәр еллар үткәч бу китапханәнең аянычлы язмышы турында хәбәрләр тарала. Тарихчы Газиз Гобәйдуллин 1926 елгы бер чыгышында Мәрҗани китапханәсенең 1922 елда янгында юкка чыгуын искә алып үтә[4]. Археограф-галим Сәед Вахидинең «Мәрҗани көтепханәсе һәм аның соңгы язмышы» исеме белән 1929 елда махсус мәкаләсе басыла[5]. Мәкалә

---

[1] Фәтхиев А. Татар әдипләре һәм галимнәренең кульъязмалары. - Казан: ун-тет нәшр., 1986. - Б. 151.

[2] Фәтхиев А. Татар әдипләре һәм галимнәренең кульъязмалары. 5 чыгарылыш. - Казан, 1960. - Б. 19-30.

[3] Әмирхан Ф. Әсәрләр: Дүрт томда. Т. 3: Публицистика. - Казан: Татар. китап нәшр., 1989. - Б. 239.

[4] Газиз Гобәйдуллин: Фәнни-биографик җыентык=Газиз Губайдуллин: Научно-биографический сборник / Төз. С. Гобәйдуллин, Э. Кульпин-Гобәйдуллин, Р. Мәрданов, И. Һадиев.- Казан: Рухият, 2002. - Б. 116.

[5] Вахиди С. Мәрҗани көтепханәсе һәм аның соңгы язмышы// Безнең юл. - 1929. - № 6/7. - Б. 14-17.

авторы Мәрҗани китапханәсенең оешу тарихы, анда XII, XIII, XIV йөзләргә караган борынгы кыйммәтле кульязма китаплар булуы турында тәфсыйльле мәгълүмат бирә. С. Вахиди Мәрҗани китапханәсенең гыйльми әһәмиятен, гаҗәеп бай мәгълүмат хәзинәсе булганлыгын аңлатып, дәлилләп яза. Мәкалә авторы гомуми нәтиҗә ясап, болай ди: «Мәрҗани көтепханәсе, шөбһәсез, бик зур, бик бай көтепханә булган. Анда әллә ничаклы, хәзерендә бөтенләй табылмый торган кульязма төп нөсхәләр, документлар, шәҗәрәләр, юридический памятниклар, авыллардан җыелган яки алардан күчереп алынган нөсхәләр бик күп булганнар»[1]. Сәед Вахиди язуына караганда, Борһанеддин гаиләсендәге Мәрҗани китапханәсенең 5 сандык күләмендәге төп өлеше 1920 елда, янгын вакытында вәйран булган[2]. Янгын афәтеннән фәкать ике капчык чамасы китап һәм язмалар калган. Мәкалә авторы моңарчы китапханәдәге китаплардан күпләр файдаланганлыгын, вакытлыча алып торган китапларны кире кайтарып бирмәүләрен, ягъни китапларның янгынга хәтле дә югалганлыгын яза. Китапханәнең болай юкка чыгуын С. Вахиди зур гыйльми байлыкны югалту дип бәяли. Шунда ук, «Мәрҗани көтепханәсеннән бик күп әсәрләр югалган һәм янып юкка чыккан булсалар да, шөбһәсез, әле анда сәламәт сакланып калганнары да байтак булырга тиеш» дип өмет тә белдерә[3]. Мәрҗани китапханәсенең янгында юкка чыгуы турында Сәед

[1] Вахиди С. Мәрҗани көтепханәсе һәм аның соңгы язмышы// Безнең юл. - 1929. - № 6/7. - Б. 16.

[2] Янгынның елы төрле хезмәтләрдә төрлечә күрсәтелә. Мәсәлән, Газиз Гобәйдуллин ут казасы 1922 елда булган дип белдерсә, Ризаэддин Фәхреддин бу турыда Мәрҗанинең улы Борһанеддиннең 1916 елда вафатыннан соң озак та үтмичә дип язган (Юсупов М. Шигабутдин Марджани как историк. - Казань: Татар. кн. изд.-во, 1981. - С. 132-133.). Ш. Мәрҗанинең «Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). - Казан: Татар. китап. нәшр., 1989» китабында 1918 ел дип күрсәтелгән (Б. 19). Безнеңчә, бу мәсьәләне үз вакытында махсус өйрәнеп, янгын вакытын 1920 ел дип язган Сәед Вахиди мәгълүматы ышанычлырак.

[3] Вахиди С. Күрсәтелгән мәкалә. - Б. 17.

Вахиди мәкаләсендәге мәгълүмат башка хезмәтләрдә дә кабатланып килде[1].

Шиһабеддин Мәрҗани китапханәсенең мирас буенча кызы Галиягә тигән өлеше 1937 елда Казан дәүләт университетына тапшырылган. Ә берникадәресе галимнең кызы Нәгыймә һәм оныгы Нажия (1919-2003) Ильясовалар кулында калган. Аларын исә Нажия ханым 1983-1986 елларда Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына тапшырган[2].

Мәрҗани китапханәсеннән кызы Хауага бүленгән өлешнең дә язмышы аянычлы. Хауа – үз чорының милләтпәрвәр җәмәгать эшлеклесе, мөхәррир һәм нашир Габдулла Апанаевның (1862-1919) җәмәгате булган. Димәк, Мәрҗани китапханәсенең Хауага мирас булган өлеше Г. Апанаевның бай китапханәсенә кушылган. Апанаевлар китапханәсенең дә совет чорындагы язмышы тәгаен генә мәгълүм түгел иде.

Ш.Мәрҗанигә бәйле кульязмалар һәм кайбер архив документлары, аерым алганда Х.Фәезхановның Мәрҗанигә язылган хатлары, әдип һәм фольклорчы Нәкый Исәнбәтнең шәхси архивында да сакланганлыгы билгеле[3]. Алар, әлбәттә, кайчандыр Мәрҗани китапханәсендә булганнар. Татар халкының бөек галиме Ш. Мәрҗани китапханәсенең язмышы, гомуми тасвирлаганда, җәмәгатьчелеккә шушы рәвештә билгеле булып килде.

Соңгы еллардагы археографик эзләнүләр нәтиҗәсендә һәм Мәрҗаниләр нәселен дәвам итүчеләрнең ярдәмнәре белән Шиһабеддин хәзрәт китапханәсенә бәйле кайбер яңа мәгълүматлар табылды. Китапханәнең буталчык тарихына да берникадәр ачыклык керде.

---

[1] Усманов М. Заветная мечта Хусаина Фаизханова: Повесть о жизни и деятельности. - Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. С. 201; Юсупов М. Шигабутдин Марджани как историк. - Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. - С. 132-133; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел... - 1989. - Б.19; Әмирхан Ф. Әсәрләр... Т.3... Б. 483 һ.б.

[2] Ахметзянов М. Указанная статья. - С. 184-185.

[3] Госманов М. Олы мирас// Казан утлары. - 1966. - № 9. - Б. 125.

Галимнең хәзер исән-сау булган оныклары 1920 елда Мәрҗани китапханәсенең янгында тулаем юкка чыгуы турындагы С. Вахиди язган вакыйганы хакыйкатькә туры килеп бетми дип белдерәләр. Бәлки, чынлап та, үз вакытында китап сорап бимазалаулардан котылу өчен галим китапханәсенең янгында вәйран булуы турындагы сүз варислары тарафыннан күпертелгән булса – гаҗәп түгел.

Мәрҗани кызы Хауаның оныгы Суфия Мостафина хатирәләренә караганда, дәү әниләре – Хауа – гаиләсендә 1920 нче еллар уртасында әле сандык-сандык китаплар булган. Икенче Бөтендөнья сугышының соңгы елларында алар яшәгән өйнең чормасында фатирда торган марҗа шәфкать туташы шунда сакланган кыйммәтле борынгы язмаларны һәм китапларны төрле максатларда һәм килешсез гамәлләрдә вәхшиләрчә файдаланып, бер өлешен исраф итүгә сәбәпче булган. Моны күреп әрнегән китап хуҗалары берничә сандык китапны таш келәткә, соңрак утын сараена күчергәннәр. Сугыштан соңгы авыр елларда явыз ниятле бәндәләр утын сараеның диварын җимереп кереп, анда булган барлык нәрсәләрне туздырганнар, яраклыларын, шул исәптән, китапларны да алып чыкканнар. Талanудан бары 40-50 данә китап калган. Ул китапларны Суфия ханым (1910 елда туган) һәм аның бертуган энесе Мәхмүт (1915-1996) Мостафиннар озак еллар кадерләп саклаганнар. Аларның бер өлешен – XVII-XIX гасырларда күчерелгән 7 кульязма һәм XIX гасырда нәшер ителгән 12 басма китапны Мәхмүт Мостафин академик Әбрар Кәримуллинга биргән булган. Ә.Кәримуллин ул кыйммәтле китапларны 1995 елның гыйнварында Татарстан Милли китапханәсенә тапшырды. Бертуган Мостафиннар 1995 елның февраль аенда Милли китапханәгә тагын 18 басма китап бирделәр. Бу хакта матбугатта хәбәр бастырган идек[1]. Шул рәвешчә Мостафиннардан Татарстан Милли китапханәсенә

---

[1]Мәрданов Р. Сирәк кульязмалар ишәя// Мәдәни җомга. - 1995. - № 2 (июль).

барлыгы 7 кульъязма һәм 32 басма китап алынды. Ул китапларның һәрберсендә диярлек «Габдулла Апанаев милке» дип язып куелган. Берничә басма китапта Ш.Мәрҗанинең кызы Хауаның автографлары бар. Котбеддин Дәһләвинең 1885 елда Һиндстанда басылган фикъһ китабында Мәрҗанинең үз автографы теркәлгән һәм шәхси мөһере сугылган[1]. Болар – Мостафиннар тапшырган китапларның бер өлеше кайчандыр Мәрҗани китапханәсендә булганлыгын турыдан-туры раслый торган дәлилләр. Ә «Габдулла Апанаев милке» дигән язма әлеге китаплар мирас буенча Хауага бирелгәннән, ягъни Апанаевлар китапханәсенә өстәлгәннән соң язылган булса кирәк.

Мәрҗани улы Борһанеддиннең оныгы Даниял Әмирханов галим китапханәсенә мөнәсәбәтле нәсел истәлекләрен үз вакытында тарихчы Миркасыйм Госмановка сөйләгән[2]. Д. Әмирхановның бу хактагы хатирәләрен безнең белән уртаклашуыннан түбәндәгеләр ачыкланды.

Мәрҗани китапханәсе өч өлешкә бүленгәндә күпчелек өлеше улы Борһанеддингә туры килгән. Борһанеддин гаиләсе 1931-1932 нче елларда Сәмәркандкә киткән вакытында Мәрҗани китаплары һәм язмаларының бер өлешен үзләре белән алган. Китапханәнең төп өлеше йортта, хуҗа сыйфатындагы бер кардәшләре кулында калган. Соңгылары авыр сугыш елларында төрле сәбәпләр аркасында китапларны саклауга тиешле игътибар бирә алмаганнар. Һәвәскәр тарихчы Шамил Сафин 1940 нчы елларда Мәрҗани кульъязмаларына пәрәмәчләр төреп сатучы бер кеше аша белешеп, шактый талану һәм туздырылуга дучар ителгән китапханәнең эзенә төшә. Тик Ш. Сафинның бу хактагы хәбәренә ул вакыттагы гыйльми оешмалар игътибар бирмиләр. Сафин Мәрҗани

---

[1] Китап Татарстан Милли китапханәсенең Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә «Т 1466108» шифры белән саклана.

[2] Госманов М. Каурый каләм эзеннән: Археограф язмалары / Тулыл. икенче басма. - Казан: Татар. китап нәшр., 1994. -Б. 303.

китапханәсеннән ике капчык күләмендәге китапларны соңрак үзенә алуга ирешә. Бу турыда ул: «...Ш. Мәрҗанинең китаплары вакытлар үтү белән төрле якка сибелгән. Аларны мин дә күп еллар буе эзләдем һәм, ниһаять, 1973 елда Ш. Мәрҗанинең оныгы Габделхәмиттән калган китапханәдән 300 гә якын китап һәм кулъязма таптым. Алар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына сатып алындылар»[1]- дип яза. 1980 нче елларда вафат булган Ш. Сафинның шәхси архивы барланып, 1992 елда «Казан» милли мәдәният музеена алдырылган. Кулъязмалар, иске басма китаплар, журналлар һәм фоторәсемнәрдән гыйбарәт булган бу бай тупламада Ш. Мәрҗани китапханәсенә бәйле материаллар да булуы билгеле[2].

Китапханәнең Сәмәркандкә алып кителгән өлешеннән кайбер язмаларны 1969-1970 нче елларда Борһанеддиннең кызы Разия Казанга кайтарткан. Бу хәзинәдәге ике кулъязманы, ягъни Хөсәен Фәезхановның «Ислахе мәдарис» һәм «Рисалә» исемле автографик хезмәтләрен Мәрҗани оныклары Даниял Әмирханов белән Нажия Ильясова 1986 елда М.Госмановка тапшыралар[3]. Фәезхановның хәзерге вакытта Казан дәүләт университетының Фәнни китапханәсендә саклана торган бу кулъязмалары фән өчен аеруча мөһим табышлардан булды. Чөнки алар Мәрҗани китапханәсе белән бергә янгында юкка чыкканнар дип исәпләнәләр иде.

Кызыклы фәнни табышлар әле болар белән генә чикләнмәгән икән. Чөнки Мәрҗани китапханәсеннән калган кыйммәтле истәлекләр тагын табылды. Даниял Әмирхановларда сакланган, моңарчы гыйльми даирәләрдә мәгълүм булмаган кулъязмалар белән беренче мәртәбә безгә

---

[1] Сафин Ш. Шиһабетдин Мәрҗани кулъязмасы// Казан утлары. - 1982.-№ 4. - Б.171.
[2] Минһаҗева И. Милли музей – хәтер хәзинәбез// Гасырлар авазы =Эхо веков. -1999. - № 1/2. -Б. 19-20.
[3] Усманов М. Автографы Марджани на полях подлинников проекта Хусаина Фаизханова о школьной реформе// Марджани: ученый, мыслитель, просветитель. - Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. - С. 121-122; Госманов М. Каурый ... - Б. 301-306.

якыннан танышу 1997 елның декабрендә насыйп булды. Болар – Мәрҗани китапханәсенә нисбәтле, Разия Әмирханова Сәмәркандтәге туганнарыннан кайтарткан кульязмалар. Д. Әмирханов үзләренең гаилә архивларында сакланган әлеге кыйммәтле мирасны 1998 елның октябрендә Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә тапшырды. Китапханәгә кабул итеп алынган кульязма истәлекләр түбәндәгеләр:

1. «Мәрҗани хәзрәтләренең әсами көтебе». Кульязма дәфтәр. 25 кәгазьдә. Елы юк. Ахыры юк.

2. Ш.Мәрҗанигә шәкерте Гаяседдин[1] язган хат. 1 кәгазьдә. Елы юк. 1870 елга хәтле язылган. Кәгазьнең икенче ягында Ш. Мәрҗани кулы белән «Утыз йиде хәлифәдер...» шигыре язылган.

3. Мәрҗанигә шәкерте Нурелгаян Карани[2] язган хат. 1293 ел, 14 рәҗәб/1876 ел, 5 август. 1 кәгазьдә. Кәгазьнең икенче ягында Мәрҗанинең Казан татар укытучылар мәктәбе (КТУШ) ачылганда, 1876 елда укыган нотыгы караламасының бер өлеше язылган[3].

4.Мәрҗанинең КТУШ ачылганда укыган нотыгының караламасы[4]. 1 кәгазьдә. 1876 ел.

5. Мәрҗанигә энесе Садреддиннең хаты. 1 кәгазьдә. Елы юк.

6. Мәрҗанигә сеңлесе Фатыйманың ире Фәйзрахман язган хат. 2 кәгазьдә. Елы юк.

7. Мәрҗанигә Әхмәд Таҗеддин исемле шәхес язган хат. 1 кәгазьдә.1287/1870 ел.

8. Мәрҗанигә Сәлимгәрәй мөфти язган хат. 2 кәгазьдә. Елы юк.

---

[1]Гаяседдин бине Хәбибулла турында кара: Мәрҗани... - 1915. - Б. 114-115; Шиһабетдин Мәрҗани/ Төз. Р. Мәрданов, Р. Миңнуллин, С. Рәхимов. - Әлмәт: Рухият, 1998. - Б. 106.

[2] Нурелгаян бине Гайнекамал Карани турында кара: Мәрҗани... - 1915. - Б. 117; Шиһабетдин Мәрҗани... - 1998. - Б. 108.

[3] Бу нотыкның тексты басылган: Мәрҗани... - Б. 130-131; Шиһабетдин Мәрҗани... - 1998. - Б. 118-119.

[4] Шунда ук.

9. Мәрҗанинең дини мәсьәләләр буенча гарәп телендәге төрле язмалары. 12 кәгазьдә. Елы юк.

10. Мәрҗанинең шәригатькә караган аерым бер мәсьәләдә язган хатының караламасы. Адресаты күрсәтелмәгән. 1 кәгазьдә. Елы юк.

11. Казан имамнары тарафыннан Мәхкәмәи шәргыягә Мәрҗани өстеннән язылган рапорт-шикаять күчермәсе[1]. 1 кәгазьдә. 1873 ел.

12. Мәрҗанинең 1879 елда Кукубин матбагасында басылган Коръән китабының хаталарын тикшерү-төзәтү өстендә эшләгән кәгазьләре. 11 кәгазьдә.

13. Хәбибҗәмал Әхмәдҗан кызының мирас акчасын алу турында распискасы. Ш. Мәрҗани кулы белән язылган. 2 кәгазьдә. 1871 ел.

14. Вәли Апанаев һәм хатыны Нәгыймә Үтәмешеваның аерылышулары турында язма. Ш. Мәрҗани кулы белән язылган. 2 кәгазьдә. Елы юк.

15. Бәһаведдинев М.-Борһанеддин Шиһабеддин улының вафаты турында белешмә. 1 кәгазьдә. 1916 ел.

16. Казембекның фарсы телендәге язмасы. 1 кәгазьдә. Елы юк.

17. Әмирханов Гомәр һәм Шиһабеддинова Разиянең никахлары турындагы таныклык. 1 кәгазьдә. 1924 ел.

18. Хөсәен Фәезхановның «Касимский ханлыгы», «Казан ханлыгы» һәм Болгар дәвере эпиграфикасы турындагы гыйльми хезмәтләре. Хөсәен Фәезханов кулы белән язылган. 30 кәгазьдә. 1850-1860 нчы еллар.

19. Мәдрәсәләрдә укыту тәртипләренә багышланган язмалар. Хөсәен Фәезханов кулы белән язылган. 1 кәгазьдә. Елы юк.

20. Болгар, Алтын Урда һәм Казан ханнары дәверләрендәге вакыйгаларны тасвирлаган «тәварих». 14 кәгазьдә. Елы юк.

21. Дини эчтәлекле кулъязма китап. XIX гасыр башы.

---

[1]Бу шикаять турында язылган һәм текстының бер өлеше басылган: Мәрҗани... - 1915. - Б. 161-162; Шиһабетдин Мәрҗани... - 1998. - Б. 140-141.

Шиһабеддин Мәрҗанигә бәйле әлеге материаллар фән дөньясы өчен, һичшиксез, зур гыйльми әһәмияткә ия. Ә Хөсәен Фәезхановның монда күрсәтелгән тарихи хезмәтләре фәнни даирәләрдә бөтенләй билгесез иделәр. Аларның табылуы – татар тарихы өчен мөһим яңалык. Фәезхановның мондый исемнәрдәге аерым тарихи хезмәтләр язганлыгы турында моңарчы мәгълүмат аз һәм саран иде. Мәсәлән, ул үзе остазы Ш.Мәрҗанигә 1865 елның март аенда язган бер хатында гомуми генә бер ишарә белән бу турыда белдереп үткән[1]. Ш. Мәрҗани Фәезхановның вафатыннан соңгы бер хатында бу уңайдан «...Болгар вә Казан хакында мәкаләсе булса кирәк иде...»[2] дигән бер җөмлә язганлыгы билгеле иде. Тарихчы Ризаэддин Фәхреддин дә Хөсәен Фәезхановның «тарих хакында һәм Русия мәдрәсәләре тугрысында язмыш әсәрләре кәнде вафатыннан соң заигъ улдыгы мәрвидер» дип язган[3]. Болардан тыш, Газиз Гобәйдуллин «Мәрҗанинең көтепханәсендә материаллар арасында Хөсәен Фәезханов каләме белә язылган, тарихка даир байтак язулар бар»[4] дип искәрткән. Галим М.Госманов та Х.Фәезхановның Болгар һәм Казан ханлыкларына багышланган хезмәтләре безнең көннәргәчә сакланып калмаганнар дип язган иде[5].

Шиһабеддин Мәрҗани китапханәсенә бәйләнешле, монда күрсәтелгән соңгы табышлар турында матбугатта язмаларыбыз чыгып килде[6].

---

[1]Хөсәен әфәнде Фәезхан // Шура. - 1916. - № 19. - Б. 449.
[2]Мәрҗани... 1915. - Кушымта: Мәрҗанинең кульязмалары.
[3]Фәхреддин Ризаэддин. Асар. 2 җилд, 14 җөзъэ. - Оренбург, 1908. - Б. 435.
[4]Газиз Г. Мәрҗанинең тарихи хезмәтләре// Мәрҗани... 1915. - Б. 349; Гобәйдуллин Г. Тарихи сәхифәләр ачылганда: Сайланма хезмәтләр. - Казан: Татар. китап нәшр., 1989. - Б. 302.
[5] Усманов М. Заветная мечта Хусаина Фаизханова: Повесть о жизни и деятельности. - Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. - С. 182.
[6] Мәрданов Р. Мәрҗани китапханәсенә бәйле яңа мәгълүматлар// Мәрҗани:Тарих һәм заман. Мәкаләләр җыентыгы. - Казан: Мастер-Лайн, 1998. - Б. 116 - 120; Мәрданов Р. Шиһабетдин Мәрҗани мирасына бәйле кайбер яңа табышлар//Гасырлар авазы =Эхо веков. - 2000. - № 3/4. - Б. 184-185; Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. - 2002. - № 3. - Б. 125-137.

*кәнде - үзе*
*заигъ улдыгы мәрви - юкка чыгуы сөйләнә*
*даир - караган*

Мәрҗани китапханәсенең язмышы турында гомуми нәтиҗә ясап, шуларны әйтергә мөмкин:

– галимнең китапханәсе, үз васыяте буенча өчкә бүленгән һәм мирас буенча төп өлеше улы Борһанеддингә калган;

– Борһанеддин гаиләсендә саклаңган китапханә 1920 елда янгында юкка чыккан дигән мәгълүмат дөреслеккә туры килеп бетми;

– китапханәнең Мәрҗани варислары кулында саклаңган аерым бер өлеше 1930-1940 нчы елларда таркалган һәм юкка чыккан;

– китапханәдәге материаллар төрле елларда, өлешләп, Казан дәүләт университетына, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына, Татарстан Милли китапханәсенә, «Казан» милли мәдәният музеена тапшырылганнар һәм шуларда саклаңалар;

– галим китапханәсендә һәм шәхси архивында булган язмалар һәм китапларның берникадәр өлеше хәзер дә Мәрҗани нәселен дәвам итүчеләрдә, шулай ук башка шәхси кулларда саклаңалар.

Бөек галим китапханәсе турында тупланган мәгълүматлар аның мирасын фәнни җәһәттән тулырак өйрәнү юнәлешендә, һичшиксез, әһәмиятле яңа материаллар булып торалар. Алар Мәрҗанинең шәхесен һәм фикри даирәсен тирәнтенрәк танып белү өчен әһәмиятле.

Ш. Мәрҗанинең гаҗәеп бай китапханәсе һәм шәхси архивы совет чорында, идеологик кыйблалар алмашыну дәверендә, халык рухында милли мираска карата ихтыярсыз тудырылган курку, битарафлык кебек мәгълүм сәбәпләр аркасында таркалган һәм тузган. Бу, әлбәттә, чагыштыргысыз зур югалту. Әмма, шулай да, Мәрҗани кулъязмаларының соңгы вакыткача табылгалап торуы – берникадәр өметләндерә дә. Максатчан эзләнүләрне дәвам иткәндә яңа табышларга ирешү ихтималы да бар дип карарга кирәк.

Бу хезмәтне басмага әзерләп бетергәндә генә, 2003 елның декабрь аенда, Татарстан Милли музееның Татар мәдәнияте

әһелләренең шәхси коллекцияләре секторы мөдирәсе Рәмзия ханым Абзалина кызыклы яңалык ирештерде. Казанлы Валерий Владимирович Штунь музейга килеп Мәрҗанинең кызы Хауалар йортының сараенда хәзерге вакытта иске бер сандык һәм аның эчендә гарәп язулы китаплар да барлыгын хәбәр иткән, бушка бирергә теләвен белдергән. Музей хезмәткәрләре көне-сәгате белән барып карасалар, сандыкның да, китапларның да Мәрҗаниләр нәселенеке булуын ачыклаганнар. Китаплар музейга кайтарылгач, музей хезмәткәре, реставратор Резеда Касыймова аларны яхшылап чистарта. Ә татар дәүләт гуманитар институты студенты Илмир Касыймов кульязма һәм басма китапларны, алардагы автографларны һәм мөһерләрне өйрәнеп тасвирлый. Нәтиҗәдә, бу тупламда барлыгы ике кульязма китап, ике язма чакыру кәгазе, ике ташбасма китап һәм 15 басма китап булуы ачыклана. Кульязма китапларның берсе XVIII гасыр ахырында күчерелгән татарча Коръән тәфсире, анда Ш. Мәрҗани кызы Хауаның автографы бар. «Китабел-вөкуфел-айат» исемле икенче кульязма китап – XVII гасыр күчермәсе, монысында Мәрҗанинең кияве Габдулла Апанаев автографы бар. Чакыру кәгазьләренең берсе – Мөхәммәтҗан Аитовның Шиһабеддин хәзрәтне Корбан мәҗлесенә, икенчесе – Г. Апанаевны никах мәҗлесенә чакыру язмалары. Басма китапларның барысы да Ш. Мәрҗанинең үз әсәрләре, ягъни «Нәзурател-хак», «Әлбәркыль-вамиз», «Мөнтәхәбел-вафийәт», «Фәваидел-мөһиммә», «Хаккыль-мәгърифәт» һ.б. хезмәтләре. Аларның кайберләре берничәшәр нөсхәдә. Бу китапларда Мәрҗанинең үз култамгалары, улы Мәхмүтнең, кызы Хауаның һәм кияве Г.Апанаевның автографлары сакланган һәм мөһерләре сугылган. Хәзер Татарстан Милли музеенда саклана торган бу китап хәзинәсе – һичшиксез, Ш. Мәрҗани һәм аның варислары китапханәсенең бер өлеше. Галимнең китапханәсенә бәйле мондый табышлар киләчәктә дә булуы бик мөмкин.

Өстәп шуны да әйтик, 2003 елның ноябрь аенда татар халкының күренекле дин галиме, гарәп теле белгече, публицист, педагог һәм җәмәгать эшлеклесе, Ш. Мәрҗанинең

шәкерте Габдрахман Гомәринең (1867-1933) бай архивы Татарстан Милли архивына тапшырылды. Гаять бай бу материалларны Г. Гомәринең Мәскәү каласында яшәүче оныклары бүләк итеп бирделәр. Г. Гомәри архивында Мәрҗанигә һәм аның китапханәсенә бәйле истәлекләр һәм яңа мәгълүматлар булуы бик мөмкин.

* * *

Бу җыентыкта басыла торган китаплар исемлеге турында.

Д. Әмирхановлар тапшырган кулъязмалар арасында Мәрҗани китапханәсенең бер өлешен чагылдырган исемлек-каталог булуы зур әһәмияткә ия. Каталог кечкенә – 11х18 см форматындагы – дәфтәргә карандаш белән теркәлгән һәм беренче битендә «Мәрҗани хәзрәтләренең әсами көтебе» (ягъни, китаплар исемлеге) дип язылган. Бу кулъязма Татарстан Милли китапханәсендә «953 т» шифры белән саклана.

Исемлектә галим китапханәсендә булган татар, гарәп, фарсы, төрек, рус телләрендәге 436 нөсхә китап теркәлгән. Аларның 123 берәмлеге кулъязма һәм 313 нөсхәсе басма китаплар. Исемлекнең төп нөсхәсендә нумерация буталган. Шул сәбәпле китапларның исәбе безнең тарафтан да элегрәк ялгыш күрсәтелгән иде[1]. Тәфсыйльләп өйрәнү нәтиҗәсендә төгәл санның 436 икәнлеге ачыкланды.

Беренче караштан ук исемлекнең бик ашыгыч рәвештә язылганлыгы аңлашыла. Имлясына нигезләнеп фикер йөрткәндә, аның язылу вакытын 1920 еллар дип билгеләп була. Мәрҗани китапханәсенең исемлек-каталогы кем тарафыннан язылуы төгаен билгеле булмаса да, фаразларга мөмкин. Мәсәлән, С. Вахиди мәкаләсендә «Әфтах мулла Тәрҗемани көтепханәдәге барлык китапларның исемлеген язды. Ул исемлек әле дә Әфтах мулла кулында, Яңа Бистәдә»[2] дигән мәгълүмат бар. Әфтах мулла кул язуының башка үрнәкләре

---

[1] Мәрданов Р. Мәрҗани китапханәсенә... // Мәрҗани: Тарих һәм заман ... - Б. 119.
[2] Вахиди С. Күрсәтелгән мәкалә. - Б. 17.

белән танышлыгыбыз булмаганга, безнең кулда нәкъ шул Ә. Тәрҗемани язган китаплар исемлегенең бер өлеше дип расларга яки ул мәгълүматны инкяр итәргә мөмкин түгел.

Исемлек дәфтәренең Шәһәр Шәрәф тарафыннан язылган булуы да бик ихтимал. Чөнки дәфтәрдәге язу Ш. Шәрәфнекенә бик охшаш. 1920 еллар башында, Мәрҗани китапханәсенең исемлеге язылган вакытларда, Шәһәр Шәрәф Татарстан Җөмһүрияте Мәркәз Шәрык китапханәсенең «гарәпчә бүлек» мөдире вазыйфасын башкарган. Исемлек-каталогның Ш. Мәрҗани китапханәсен 1920 нче еллар башында Мәркәз Шәрык китапханәсенә алдыру өчен яисә исемлеген булса да теркәп алу өчен Ш.Шәрәф тарафыннан язылган булуы ихтимал. Билгеле булганча, Ш. Шәрәф 1915 елда нәшер ителгән «Мәрҗани» җыентыгына галимнең тәрҗемәи хәлен язганда китапханәдән иркен файдаланган. Бу хакта Ш.Шәрәф «...Мәрҗани көтепханәсене, Сәмәркандтә күчереп алмыш китапларыны вә язуларыны тәфтиш итәргә карар вирдек. Мулла Кәшшаф әфәнде Тәрҗемани илә бәрабәр, Мәрҗанинең көтепханәсендә улан китапларны дикъкать итеп карадык» дип һәм Мәрҗанинең оныгы Габделхәмид Борһанеддин улы китапханәнең зур бер өлешен күрсәткәнлеген язган[1]. Әлеге исемлекне язу – үз вакытында китапханә белән электән яхшы таныш булган Ш.Шәрәфкә йөкләнгән булса, бик табигый.

Бу исемлек бай китапханәнең аерым бер өлешен генә (ихтимал, балаларына мирас булып калган өч өлештән берсен генә) чагылдыра булса кирәк. Һәрхәлдә, ул очракта да, исемлек тулы түгел. Чөнки әлеге каталог кечкенә бер дәфтәрне һәм аңа өстәлеп язылган берничә бит кәгазьне тәшкил итә. Өстәмә битләр тегелмәгәннәр һәм аларның аерым-аерым хәлдә булуларыннан, текстның тәмамланмаган көенчә кинәт өзелүеннән исемлекнең тулы түгеллеге ачык күренә. Ягъни, исемлек кайчандыр тулы йөргән булса да, хәзер аның битләре

---

[1] Мәрҗани: Виладәтенә... - 1915. - Б. 51; Шиһабетдин Мәрҗани.... - 1998. - Б. 62-63.

*тәфтиш итү - тикшерү*
*улан - булган*

җитешми. Мондый исемлек дәфтәрләре берничә булгандыр дип тә фаразларга мөмкин. Ничек булса да, бу исемлек Ш. Мәрҗани ия булган китаплар белән танышып, алар хакында фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Татар халкының олуг галиме Шиһабеддин Мәрҗани китапханәсе турында тулырак мәгълүмат хасил итү өчен китапханәсенең бер өлешен чагылдырган каталогын нәшер итәргә булдык. Киләчәктә Мәрҗани мирасын өйрәнәчәк фән әһелләрен ул кызыксындырыр дип өметләнәбез.

Исемлек-каталогтан күренгәнчә, Мәрҗани китапханәсендә фәлсәфә, фикъһ, шәригать, тәфсир, хәдис, тарих, әдәбият, тыйбб, гарәп теленең сарфы белән нәхүе һ.б. күп төрле эчтәлектәге китаплар тупланган булган. Арада бер китапны галимнең әтисе Бәһаведдин язганлыгы (исемлектә 46 номерда) теркәлгән. Шулай ук кайберләрен Ш. Мәрҗани үзе күчереп язганлыгы турында да мәгълүматлар бар. Исемлектә Ш. Мәрҗани тарафыннан күчерелгән кулъязма китапларга һәр очракта да искәрмә бирелмәгән, күрәсең. Шәһәр Шәрәф Мәрҗани китапханәсендәге кулъязма китаплар турында язганда «Тәфсире казый Бәйзави», «Шәрхе һидайәт Фәтхел-кадыйр», «Таҗет-тәраҗим» исемле китапларны үзе күчергән дип белдерә[1]. Исемлектәге 33, 63, 113 номерларда теркәлгән кулъязмалар шул ук, ягъни Ш. Шәрәф телгә алган китаплар булса кирәк. Ш. Шәрәф Мәрҗани китапханәсендә Бохарадан алып кайткан китапларының аерым исемлеге булганлыгын[2] һәм Бохарадан кайтасы елында (ягъни 1849 елда) өмә итеп «Әл-җәваһирел-мазыййа фи табакател-Хәнәфийә» исемле китапны күчертеп алганлыгы[3] турында да яза. Исемлектә 4 нче номер белән теркәлгән «Җәваһирел-мазыййа...» китабы шул булса кирәк. Исемлектә Ш. Мәрҗанинең беренче мәртәбә укып, файдаланган кулъязма Коръән китабы турында да аерым искәрмә бирелгән (исемлектә 42 номерда). Монда Мәрҗанинең үз әсәрләреннән «Вафийәтел-әсляф мөкаддимәсе» һәм

[1] Мәрҗани: Виладәтенә... - 1915. - Б. 52; Шиһабетдин Мәрҗани... - 1998. - Б. 63.
[2] Мәрҗани... 1915. - Б. 62; Шиһабетдин Мәрҗани... 1998. - Б. 70.
[3] Мәрҗани... 1915. - Б. 70; Шиһабетдин Мәрҗани... 1998. - Б. 75.

өченче җилде, «Әл-хикмәтел-бәлига», «Әл-бәркыль-вамиз...», «Әл-газбел-форат...», «Хаккыль-мәгърифәт...» әсәрләре теркәлгән һ.б. кульязма җыентыклары (исемлектә 60, 69, 102, 112, 121, 122 номерларда) бар. Кульязмалар арасында Әбугалисина, Аристотель, Гарәбшаһ, Ибне Әсир, Мөтәнәбби, Газали кебек мәшһүр затларның хезмәтләре һәм әсәрләре булган. Дистәгә якын кульязма китапларның бик борынгы һәм бик нәфис булганлыклары турында кыскача хәбәрләр теркәлгән.

Басма китапларның күпчелеген Истанбул басмалары тәшкил иткән. Каталогта галимнең «Мөстәфадел-әхбар...», «Нәзурател-хак», «Әл-бәркыль-вамиз...» хезмәтләре берничәшәр нөсхәдә булганлыгы күренә. Гомумән, исемлектәге басма китаплар арасында Ш. Мәрҗанинең 32 нөсхә әсәре теркәлгән. Монда шулай ук рус телендәге «Руководство к русской истории», «Энциклопедический лексикон» кебек китапларның исемнәре дә бар. Бу уңайдан шуны искә алырга кирәк: Г.Гобәйдуллин тарихи хезмәтләрен язганда Шиһабеддин Мәрҗанинең нинди чыганаклардан файдаланганлыгын тикшерә һәм Мәрҗани файдаланган китаплар арасында Шәрык телләрендәгеләрдән тыш, русча язылганнары да булуын һәм андыйларның галим китапханәсендә дә барлыгын күрсәткән. Мәрҗанинең төрле тарихи хезмәтләрдән өзекләр һәм күчермәләр, үз фикерләре тупланган аерым җыентыклары барлыгын язып калдырган[1].

Исемлектә Ш. Мәрҗанинең вафатыннан соң чыккан кайбер китаплар да бар. Алар галимнең варислары кулында калган китапханәгә яңа китаплар да өстәлгәнлегенә ишарә итә. Мәсәлән, Мәрҗани вафатыннан соң нәшер ителгән һәм бу исемлектә теркәлгән түбәндәге китапларны күрсәтергә мөмкин.

1. «Зыййаэл-колүб». 5 җөзъэ. «Дин вә мәгыйшәт» нәшере. Исемлектә 95 номерда.

Бу китапка «Дин вә мәгыйшәт» нәшере дип бирелгән искәрмә үзе үк китапның XX гасыр башында чыкканлыгына күрсәтә. Чөнки «Дин вә мәгыйшәт» исемендәге татар журналы

---

[1]Газиз Г. Мәрҗанинең тарихи хезмәтләре// Мәрҗани... 1915. - Б. 333-358; Гобәйдуллин Г. Тарихи сәхифәләр ачылганда: Сайланма хезмәтләр. - Казан: Татар. китап нәшр., 1989.- Б 290-308.

Оренбургта 1906 елның 31 декабрендә чыга башлаган. Журнал идарәсе аерым китаплар да нәшер иткән. Күп җөзъэкисәкләрдән торган «Зыййаэл-колүб» китабы Оренбургта 1907 елда басылган.

2. Габдрахман Гомәри. «Мөгаллиме сарфи лисанел-гарәб». Исемлектә 101 номерда.

Авторы Ш. Мәрҗанинең шәкерте булган бу китап күп мәртәбәләр нәшер ителгән. Аның беренче басмасы 1896 елда басылган.

3. Ризаэддин бине Фәхреддин. «Моталәга». Исемлектә 116 номерда.

Бу китап Казанда 1897 елда басылган.

4. Берничә җөзъэдән торган «Әд-дөрусен-нәхүийә» исемле китап Казан һәм Оренбург шәһәрләрендә XX гасыр башында басылып чыккан. Исемлектә 174 номерда.

5. Шиһабеддин Мәрҗани. «Әл-кыйсьмес-сани мин китаби Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». Исемлектә 230 номерда.

Галимнең бу китабы вафатыннан соң, 1900 елда Казанда дөнья күргән.

6.Каюм Насыйриның «Ысуле җәгърафияи кәбир» хезмәтенең беренче басмасы Казанда 1894 елда чыккан. Исемлектә 260 номерда.

7. Әхмәдһади Максудиның гарәп телендәге «Мизанел-әфкяр» китабы Петербургта 1902 елда нәшер ителгән. Исемлектә 263 номерда.

8.Фатих Зәбири. «Тәмрин әт-тулляб». Исемлектә 301 номерда.

Бу китап Казанда 1909 елда басылып чыккан.

Мондый китаплар, югарыда әйтелгәнчә, санаулы гына. Исемлеккә язылган китапларның төп өлеше Мәрҗани яшәгән вакытка нисбәтле.

Исемлек теркәлгән дәфтәрдә кульъязма һәм басма китаплар аралаш язылганнар. Анда китапның исеме, авторы, кульъязмамы, басмамы, ничәнче җилде яки җөзъэсе икәнлекләре теркәлгән. Сирәк очракларда аерым искәрмәләр дә бирелгән. Алдарак

әйтелгәнчә, бу исемлек бик ашыгыч язылу сәбәпле, нумерациясе буталган булган.

Мәрҗани китапханәсе каталогындагы барлык мәгълүматлар да бераз үзгәреш һәм төзәтмәләр белән монда бирелде. Үзгәреш һәм төзәтмә дигәнебез: кульъязма китапларны басмаларыннан аерып, яңа нумерация белән күрсәттек. Бер үк исемдәге басма китаплар берничә нөсхә буларак, төп дәфтәрдә төрле урыннарда язылган булсалар да, без беренче очраган урынына башкаларын да туплап, бер җиргә җыйнап бирдек. Калган мәгълүматлар үзгәрешсез, төп дәфтәрдәге тәртиптә бирелде. Китапларның һәм авторларның исемнәрен, татарча транскрипция белән беррәттән, гарәби язылышта да бирү мәгъкуль күрелде. Бу уңайдан шуны да искәртәбез: кульъязмадагы төп текстта танылмаган яки төрлечә укылышы ихтимал булган урыннар да бар. Андый очракларда сүзләр янына безнең тарафтан җәяләр эчендә сорау билгесе куелды. Гарәби язылышлары төп нөсхәдә ничек булса, шул рәвешчә күчереп алынды. Аларда исемлекнең үз вакытында бик ашыгыч язылган булуы сәбәпле, һәр төрле ялгышлыклар киткән булуы да ихтимал. Тексттагы квадрат җәяләр эчендә бирелгән авторлар һәм китап исемнәренең аерым өлешләре безнең тарафтан өстәлде. Исемлек эчендәге аңлатмаларда очраган гарәби һәм архаик сүзләргә сүзлекчә бирелде. Бу хезмәттә китапларның исемнәрен тәрҗемә итү һәм гыйлемнең кайсы тармагына нисбәтле булуларын ачыклау, классификацияләү һәм шәрех-аңлатмалар бирү бурычы куелмады.

Бу хезмәтнең ахырындагы «Кушымта» өлешендә галимнең китапханәсе турындагы башка мәгълүматлар да бирелде. Ягъни, 1915 елда нәшер ителгән «Мәрҗани» җыентыгындагы Ш. Мәрҗани китапханәсен тасвирлаган аерым өзекләр һәм археограф С.Вахидинең Мәрҗани китапханәсе язмышына багышланган мәкаләсен дә җыентыкка кертү кирәк табылды.

Раиф Мәрданов,
филология фәннәре кандидаты.

# Мәрҗани китапханәсенең исемлек-каталогы

## Кулъязма китаплар

| № | Авторлар | Исеме | Җилд яки җөзъә | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Куртуби<br>قرطبى | Тәфсире Куртуби<br>تفسير قرطبى | «Хаҗ», «Йасин», «Сүрәи Рәхман» | |
| 2. | | Гаййәтел-бәйан<br>غاية البيان | 3 җилд соңы | |
| 3. | Ибне Кәсир әш-Шафигый<br>ابن كثير الشافعى | Тәфсир<br>تفسير | 1 җилд | |
| 4. | | Җәваһирел-мөфид вә фи табакател-Хәнәфийә<br>جواهر المفيد و فى طبقات الحنفى | 1 җилд | |
| 5. | | Холәсател-фәтва<br>خلاصة الفتوى | 1 җилд | |
| 6. | | Һидайә<br>هدايه | 1 җилд | |
| 7. | Әбү Гали әш-шәйех әр-рәис ибне Сина | Китабел-канун фит-тыйбб (мәга бәгъзе тәэлифиһи вә һуа гыйльмет-тыйбб вә гыйльмел-мантыйк вә гыйльмел-кәлям вә гыйльмет-табигый) | 1 җилд | нәфис китап |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | للابى على ابن سينا | гыйльмет-табигый)<br>كتاب القانون فى الطب (مع بعض تاءليفه و هو علم الطب و علم المنطق و علم الكلام و علم الطبيعى) | | |
| 8. | Шәйбан әл-Мәзәри әл-мәгъруфиһи би-Ибне әл-Әсир<br>للشيبان المزرى المعروفه بابن الاثير | Җамигыль-ысул фи әхадисер-рәсүл<br>جامع الاصول فى احادث الرسول | соңгы җилд<br>جلد اخر | |
| 9. | | Шәрхе тәлхыйсел-мифтах әл-мүсәммә бил-мотаувәл<br>شرح تلخيص المفتاح المسمى بالمطول | 1 җилд | |
| 10. | | Китабет-тәлвих<br>كتاب التلويح | 1 җилд | |
| 11. | | Тәфсире мәдарик<br>تفسير مدارك | «Сүрәи Мәрйәм»-нән ике җилд тәмамән, башлап ахырынача | |
| 12. | | «Мөхтәсар» шәрхе «Гали әл-Карый» | «Китабет-тәһа- | Мәржани |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | على القارى شرح مختصر | рәт»тән башлап ахыры-нача | хәзрәтлә-ренең үз кулы белән язылган китап |
| 13. | Әл-Бәззаз<br>البزاز | Әл-фәтави әл-Бәззазия<br>الفتاوى البزازيه | | |
| 14. | | Фикъһел-әкбәр шәрхе<br>فقه الاكبر شرحى | | |
| 15. | | Тарикаи Мөхәммәдия<br>طريقهء محمديه | | |
| 16. | | Холәсател-вәфа би-әхбари дарел-Мостафа<br>حلاصة الوفا باخبار دار المصطفى | | нәфис китап |
| 17. | Имам Малик<br>امام مالك | Мөваттаэ имам Малик<br>موطاء امام مالك | 1 жилд | |
| 18. | | Әл-мөнтәхәб фил-өмур әл-гаммәт<br>المنتخب فى الامور العامة | | |
| 19. | | Әнмүзәҗ<br>انموذج | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 20. | | Шәрхе шәригател-ислам<br>شرح شرعة الاسلام | | |
| 21. | | Һидайә<br>هدايه | 1,2 җөзъэ | |
| 22. | Гали әл-Карый<br>لعلى القارى | Шәрхен-никайә мөхтәсарел-викайә<br>شرح النقايه محتصر الوقايه | | |
| 23. | | Гомдател-хиффаз фи тәфсири әшрәфел-әлфаз<br>عمدت الحفاظ فى تفسير اشرف الالفاظ | 1 җилд | |
| 24. | | Казый әл-мөбарәк лисәллямел-голум<br>قاضى المبارك لسلم العلوم | | |
| 25. | | Фәтхел-мөбин шәрхел-әрбә-гыйн<br>فتح المبين شرح الاربعين | | |
| 26. | | Йәзбәх Мәгъриби<br>يزبح مغربى | | нәфис китап |
| 27. | Мәүлана Йосыф әл-Карабагый<br>لمولانا | Тәгъликат галәл-гакаидел-гыйздийә<br>تعليقات على عقائد | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | يوسف القراباغى | العضديه | | |
| 28. | Әбел-габбас Әхмәд бине Гоммар әт-Тәмәйәмми әл-Мәһдеви<br>لابى العباس احمد بن عمار التميمى المهدوى | Китабет-тәхсыйль лифәваидет-тәфсыйль<br>كتاب التحصيل لفوائد التفصيل | 2 җөзъэ | |
| 29. | Мөхәммәд бине Әсгадь әш-Ширази<br>لمحمد بن اسعد الشيرازى | Хәваши галәш-шәрхел-җәдид лит-тәҗрид<br>حواشى على الشرح الجديد التجريد | | |
| 30. | | Зәһрәтер-рийаз вә нәзһәтел-колуб әл-мәраз<br>زهرة الرياض و نزهة القلوب المراض | | |
| 31. | | Хашийәте Дауд әл-Опый<br>حاشية داود الاشى | | |
| 32. | | Хашийәте ли-казый Мөбарәк | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | حاشية لى قاضى مبارك | | |
| 33. | | Тәфсире казый Бәйзави<br>تفسير قاضى بيضاوى | 3 җөзъэ | |
| 34. | Мөтәнәбби<br>متنبى | Диване Мөтәнәбби<br>ديوان متنبى | | |
| 35. | Җәлаледдин әд-Дәвәни<br>لجلال الدين الدوانى | Хашийәте галә шәрхел-гака-ид<br>حاشية على شرح العقائد | | |
| 36. | Әхмәд бине Мөхәммәд әт-Тәхауый<br>احمد بن محمد الطحاوى | Шәрхе асар ли-имам Әбү Җәгъфәр<br>شرح آثار لامام ابى جعفر | 1 җилд | |
| 37. | | Сарфы гарәби<br>صرف عربى | | |
| 38. | | Хашийәте мәүләви Садыйк галә шәрхел-исагуҗи<br>حاشية مولوى صادق على شرح الاساعوجى | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 39. | Мөхәммәд Әл-Һәрәви<br>محمد<br>الهروى | Хисныль-хассыйн шәрхе<br>حصن الحصين شرحى | 1 җилд | |
| 40. | | Тәһзибел-кәлям шәрхе<br>تهذيب الكلام شرحى | | |
| 41. | | Фосуле истирушәйни<br>فصول استروشينى | 1 җилд | |
| 42. | | Коръәни кәрим<br>قرآن كريم | 1 җилдтә язма Коръән булып, остазе дамелла Шиһабеддин әл-Мәрҗани беренче мәртәбә шул Коръәннән укыдыгыны ахырына язмыш. Бу Коръән тәмам түгел, сүрәи «Фәтех»кә кадәр генә | |
| 43. | | Һәдийәтес-сагълук<br>هدية الصعلوك | 1 җилд | |
| 44. | | Китабет-тәнкыйх мәга шәрхи әл-мүсәммә бит-тәүзих<br>كتاب التنقيح مع شرح<br>المسمى بالتوضيح | 1 җилд | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 45. | | [Шул ук] | | янә бер нөсхә |
| 46. | Бәһаведдин әл-Мәрҗани<br>ابن جمع بهأ الدين المرجانى | Мәҗамигы Бәһавийә<br>بجامع بهائيه | 1 җилд | |
| 47. | | Шәрхе тәлхыйсел-мифтах<br>شرح تلخيص المفتاح | 1 җилд | |
| 48. | Мөхәммәд бине Мөхәммәд әл-мөләкъкәб би-ахрид Дамад әл-Хәсәни<br>لمحمد بن محمد الملقب باخر الداماد الحسنى | Бер язма китап (исемен белмәдем) | 1 җилд | |
| 49. | | Хашийәтел-мөхаккак әл-Һәрәви галә шәрхет-тәһзиб<br>حاشية المحقق | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | الهروى على شرح التهذيب | | |
| 50. | Габдел-мөс-тәһәди Нурелгайан әс-Сәлими<br>للعبد المستهدى نورالعيان السلمى | Язма кәгазьләр. Тышына «Лил-Габдел-мөстәһәди Нурелгайан әс-Сәлими» [дип язган] | | |
| 51. | | Хашийәте шәрхел-әбел-бәка<br>حاشية شرح الابو البقاء | | язма иске китап |
| 52. | | Фәраиз<br>فرائض | | |
| 53. | | Фикъһыдән язма иске бер китап<br>فقه | 1 җилд | |
| 54. | Шәйхе Шиһабеддин әс-Сәһрәвәри<br>للشيخ شهاب الدين | Әл-гавариф фил-мәгариф<br>العوارف فى المعارف | 1 җилд | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | السهرواری | | | |
| 55. | | Мөниятел-мөсаллә шәрхе<br>منية المصلى شرحى | | |
| 56. | | Мелла Җөлал бинһи шәрхе тәҗрид<br>ملا جلال به شرح تجريد | | |
| 57. | | Шәрхе гакыйдәтел-имам әт-Тәхави<br>شرح عقيدة الامام الطحاوى | | нәфис китап |
| 58. | | Рисаләи шәмсийә<br>رسالهء شمسيه | | |
| 59. | | Мисбахел-өнес бәйнәл-мәгъкуль вәл-мәшһүр фи шәрхи мифтахи гайбел-җөмегъ вәл-вөҗүд<br>مصباح الانس بين المعقول و المشهور فى شرح مفتاح عيب الجمع و الوجود | | |
| 60. | [Шиһабеддин Мәрҗани] | Мәрҗани хәзрәтенең «Әлбәркыль-вамиз [галәл-бәгыйз әл-мүсәммә бин-накыйз»]еннән һәм башка бәгъзе язмала- | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | [شهاب الدين المرجانى] | рыннан гыйбарәт мөҗәлләд язма китап<br>البرق الوميض على البغيض المسمى بالنقيض... | | |
| 61. | | Сөлләмел-голум<br>سلم العلوم | | |
| 62. | | Фәраизе Сиражийә<br>فرائض سراجيه | | тәмам түгел |
| 63. | Шәйхе Касыйм Котлыбуга әл-Җәмали<br>لشيخ قاسم الجمالى قطلبغا | Китабе таҗет-тәраҗим<br>كتاب تاج التراجم | | |
| 64. | | Фикъһыдән бер китапның уртасы<br>فقه | | |
| 65. | Аристотель<br>لارسطاطالس المعروف | Китабе әсулуҗия<br>كتاب اسولوجيا | | нәфис китап |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | الفيلسوف | | | | |
| 66. | | Мифтахер-рисалэтил-жэдидэт эн-нафи(?) мэгърифэт гозреш-шэһур<br><br>مفتاح الرسالة الجديدة<br><br>النافى معرفة غزر الشهور | | | |
| 67. | Котб эл-Мэкки<br><br>لقطب<br><br>المكى | Игъламе би-игълам бэлэде Аллаһи эл-хэрам фи тарихи Мэккэ<br><br>اعلام با علام بلد الله<br><br>الحرام فى تاريخ مكة | | | |
| 68. | | Гакаиде Нэсэфи<br><br>عقائد نسفي | | | |
| 69. | [Шиһабед-дин Мэр-җани]<br><br>[شهاب<br><br>الدين<br><br>المرجانى] | Эл-җилдес-салис мин китаби Вафийэтел-эсляф<br><br>الجلد الثالث<br><br>من كتاب وفية الاسلاف | | | |
| 70. | | Һидайэ<br><br>هدايه | 1 җилд | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 71. | | Шәрхе һидайәтел-хикмәт<br><br>شرح هداية الحكمت | | нәфис китап |
| 72. | | Язма бер китап. Тарихе Болгарга даир язмалар да бар<br><br>تاريخ بلغار و الخ... | | |
| 73. | | Фарсы телендә язма китап | 1 җилд | |
| 74. | | Мотаувәл галәт-тәлхыйс<br><br>مطول على التلخيص | | |
| 75. | | Мир Бакыр Дамад<br><br>مير باقر داماد | | |
| 76. | | Ысуле фикъһтан язма китап<br><br>اصول فقه | | гайре тәмам |
| 77. | | Исагуҗи<br><br>ايساعوجى | | |
эннәһер», «Шәрхи мокаддимәтир-рисаләтиш-шәмсийә» хезмәтләрен Бохарада вакытында язган.

Бохарада вакытында укыган китапларын дикъкать белән һәм тәфсыйльләп үзләштереп, төрле китапларда күргән әһәмиятле мәгълүматны, үзенең хәтеренә килгән нәрсәләрне шул китапның читенә яза барган. Бохарада вакытында «Гакаиде Нәсәфи», «Мелла Җәлял» китаплары читләрендә мондый язулар байтак күренде. Шуңа күрә шул китапларга язылган аңлатмаларның кайбер урыннары Бохарада язылган дип хөкем итәргә мөмкин. Ләкин боларның күбесе Казанга кайтканнан соң тулыландырылган вә төзәтелгәннәр...

Мәрҗани хәзрәтләре гыйлем кирәк-яракларына, хәтта кечкенә генә кәгазьләргә дә бик ихтирамлы булган. Җыентык вә китапларын актарганда күренә ки, ул үзенә килгән хатларның гына түгел, хәтта кечкенә кәгазьдә булган чакыруларның вә хатларның да әрәм булуына вә ташлануына разый булмаган. Кулына төшкән һәр төрле хат вә кечкенә кәгазьләрне дә бер җиргә җыеп төпләгән. Яки берәр нәрсә язып, җыентыклары янына ябыштырып куйган.

Мәрҗани бик дикъкатле, зур игътибар иясе булган. Бохарада вакытыннан башлап, кирәк булуы ихтимал булган һәр төрле нәрсәләрне, китапларда күренгән әһәмиятле сүзләрне күчереп алып теркәп барган. Аның китапханәсендә күпсанлы зур җыентыклары, вә берничә хатирә дәфтәрләре бар. Хатирә дәфтәрләренә әһәмиятле вакыйгаларны, мәҗлесләрдә берәр кешенең тарихына яки нәсәбенә бәйле ишетелгән сүзләрне, әһәмиятлерәк сүзләр, ятрак хәбәрләрне, игътибарлы кешеләрдән Казанга килеп-китүчеләрне, читкә биргән вә алган китапларын, һәр төрле мөгамәләләрен, алыш-биреш, керемнәр вә чыгымнары вә кайбер төшләрен вә болардан башка онытылмаска тиешле булган кайбер фикер вә хатирәләрен кыска рәвештә булса да язып куйган.

Мәрҗанинең әһәмият биргән нәрсәләреннән берсе — борынгы әйберләр булган. Ул һәр төрле иске акчалар, иске китаплар, иске язуларга, һәр төрле борынгы әйберләргә, кабер

ташларына вә болардан башка һәр төрле борынгы нәрсәләргә әһәмият биреп җыйган вә теркәгән. Ата-бабалардан һәр кайсының берәр төс нәрсәсен иң кадерле әйберләре урынында саклаган. Бабасыннан калган бер чүлмәк хакында: «Башка кешеләр чүлмәккә ун тиен дә бирмәсләр. Ләкин мин ун мең сумга да сатмыйм» дип сөйләгән. Үткәндә язылган васыятьнамәсендә дә, борынгы әйберләргә ни дәрәҗәдә әһәмият бирүе күренеп тора. Үзенең хатирә дәфтәрендә ошбу сүзләрне яза:

«Борынгы әйберләрем: бер бит Госман Коръәне, 16 данә Габбаси хәлифәлеге акчалары, вә алардан башка иске акчалар, әтиемнең әнисе Зәгыйфә бинте Габделбакыйдан калган бер таяк илә кечкенә саксон чынаяк, әниемнең әнисе Мәхбүбә бинте Туктамыштан калган калын табак, әнкәмнән калган кара тимерле сандык, әткәмнән мирас булып калган касә вә чынаягы, вә болардан башка каләмем берлә һәм атам Бәһаведдин бине Сөбхан хәзрәтләре каләме илә һәм әтиемнең әтисе дамелла Сөбхан бине Габделкәрим әл-Мәрҗани хәзрәтләре каләме илә язылган китаплар һәм бабамның бер олы апасы тарафыннан язылган җыентык, әниемнең әтисе Габденнасыйр бине Сәйфелмөлек әл-Җәбәли хәзрәтләре каләме илә язылган «Тәүзыйх вә Тәлвих» вә «Шәрхел-мөкаддимәтел-Җәзәрийә», бабабыз бабасының атасы Мортаза бине Галидән калган «Мәтнел-фәраиз» вә кайбер язмалары. Якут әл-Мөстәгъсами кулы илә язылган «Ахыры җамигыль-ысул», Газзали заманасыннан аз гына соңрак, 575/1179 елда язылган «Мәҗмугаи асаре Газзали», мәшһүр Мортаза әфәнденең 1110/1699 елда язылган «Иҗазәтнамәсе», Ибраһим бине Хозыр әл-Болгари язган 751/1350 ел белән даталанган «Китабе ысул» ахырында шәех Әбү Мөхәммәдсадир бине Галәведдин әл-Болгариның 766/1365 елда язылган «Иҗазәтнамә»се булган «Ысуле Фәхрел-ислам» китабы. Бу югарыда әйтелгән әйберләрне балаларым һич тә ятларга чыгармый, үзләре мөбарәк дип сакласыннар».

*(Шиһабетдин Мәрҗани. - Әлмәт: Рухият, 1998. - Б. 62-63, 69-73, 75, 76, 155, 156).*

# Мәрҗани көтепханәсе һәм аның соңгы язмышы

Мәсьәлә тулырак һәм ачыграк аңлашылсын өчен сүзне эшнең тарихи ягыннан, кыскача гына Мәрҗанинең тәрҗемәи хәлен язудан башлыйк.

Мәрҗани Казан өязе (Арча кантоны, Япанчы авылында[1]) 1818 ел, гыйнвар 3 ендә туган. 1889 ел, апрель 18 ендә, 74 яшендә Казанда үлгән[2]. Ул яшьтән үк таза тәнле, Сабан туйларында көрәшче батыр булып, көрәшеп йөргән. Аны «көрәшче Шиһаби»[3] дип йөрткәннәр. Мәрҗанинең яшь вакыттагы тәрбиясе авыл мәктәпләрендә булып, ул кечкенәдән үк тарихи хикәяләр тыңларга бик яраткан. Ләкин авыл тормышы, авыл мәдрәсәләрендәге укулар аны канәгатьләндермәгәннәр; ул 1838 нче елда Бохарага укырга китә[4]. Бохара вә андагы мәдрәсәләр һәм укыту ысуллары Мәрҗанигә бер дә ошамыйлар. Шуннан соң ул, әүвәле Бохарада, аннан соң Сәмәркандтә төрле көтепханәләргә йөреп, андагы кульъязмаларны тикшерү һәм өйрәнү эше белән шөгыльләнергә керешә. Аның бу хезмәте унбер елларга сузыла. Шушы унбер ел эчендә Мәрҗани бик күп кульъязмаларны күчереп язып ала һәм башкалардан күчертә. «Вафийәтел-әсляф», «Мөстәфадел-әхбар» һәм «Мәрҗани» мәҗмугасендә язылган мәгълүматларга караганда, ул Бохара һәм Сәмәрканд якларыннан күп санда кульъязма китаплар һәм башка тарихи материаллар алып кайткан.

---

[1]Япанчы авылы - Казанның төньягында илле чакрым ераклыгында Мәрҗан авылы якынында бер авыл.
*(С.Вахиди иск.).*

[2] «Мәрҗани» мәҗмугасе. - 8 биттә. *(С.Вахиди иск.).*

[3] «Мәрҗани» мәҗмугасе. - 13 биттә. *(С.Вахиди иск.).*

[4] Мәрҗанинең «Бохара сәяхәтнамәсе» исемендә зур гына кульъязма бер китабы бар. *(С.Вахиди иск.).*

Мәрҗанинең язуына караганда, аның ата һәм бабалары да тарихчы кешеләр булганнар. Ул «Мөстәфадел-әхбар»да үзенең бабаларыннан байтак тарихи вакыйгаларны күчереп яза. 1877 нче ел, июль 31 еннән август 18 енә чаклы дәвам иткән IV нче Археология съезды выставкасының күрсәтмәсендә (указатель) язылган мөһим кульъязмаларның эчендә Мәрҗанинең Габделкәрим (бу кеше йөз яшендә, 1205 һиҗридә[1] Мәрҗан авылында вафат) исемле бабасыннан калган бер кульъязма Коръән бар иде. Бу кульъязма Коръән турында Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар» II җилд, 142 биттә болай яза: «Бабабыз Габделкәрим Мәрҗанидән калган, баш ягыннан ике кәгазь, ахыр ягыннан һәфтияк өлеше төшкән, рәсме хатты бик гүзәл, укымышлы кеше тарафыннан язылган бер Коръән кулыбызда бар иде. Бу кульъязма Коръәннең кәгазе безнең җиребездә иске заманнарда истигъмаль ителгән борынгы кәгазь бар иде. Карасы: мазу, күкфараз һәм сәмихтан кушылып ясалган иде. Һәрбер җөзъэнең башында (җөзъэ – Коръәннең утыздан бере, Коръәндә утыз җөзъэ бар) бер юл язу бөтенләй куе кара калын каләм белән язылып, һәрбер җөзъэнең дүрттән беренең алдынгы беренче сүзе дә шулай ук калын итеп язылган иде. Бу кульъязма Коръәнне бабабыз Сөбхан Габделкәрим угылы Мәрҗани үзенең ата ягыннан булган кардәше, бер кыз тарафыннан язылган булганлыгын сөйлидер иде. Кат-кат ишеткән идем. Ләкин ул вакытта яшьлек гафләте сәбәпле ул (мәзкүр Коръәнне язучы) кызның исемен, шәмаилен вә башка аның хәлләрен тәфсилләп язып кала алмаганлыгыма бик зур тәәссеф итәмен».

Мәрҗанинең озак яшәгән берничә буын бабаларыннан бирле җыелып килә торган бай көтепханәгә варис уларак, хуҗа

---

[1]1205 һиҗри ел - 1791 милади елга туры килә (*Р. Мәрданов искәрмәсе*).

*җилд - том*
*мазу - чикләвек*
*күкфараз - купорос*
*сәмих - ?*
*җөзъэ - кисәк, өлеш*
*гафләт - игътибарсызлык, ваемсызлык*
*мәзкүр - шул, исеме алда әйтелгән*
*рәсме хатт - язу, почерк*
*шәмаил - холык*
*тәәссеф - үкенү*
*уларак - буларак*

булып калуы мәгълүм. Менә моннан күренә ки, Мәрҗани көтепханәсенең башлап нигезләнүе, Бохара вә Сәмәрканд һәм, гомумән, Төркестан ягыннан үзе алып кайткан күп сандагы кулъязма һәм документлар белән ата-бабаларыннан аңар мирас булып калган, кулъязмага бай борынгы көтепханәнең кушылуыннан килеп чыккан бер көтепханә булган.

Мәрҗани Казанда мөдәррис булып торган заманнарында Казаннан читтә булган төрле татар авылларына йөреп, кулъязмаларны, кабер ташларын һәм документларны тикшергән, җыйган. Ул бик күп авылларда булган[1]. «Мөстафадел-әхбар»да Мәрҗани үзенең төрле авылларга йөреп тикшергәннән кулга төшергән кулъязма һәм документларга таянып бик күп нәрсәләр яза.

Мисал өчен кайберләрен күчереп язып китик. Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар» (1 кыйсем) 22 биттә Казан сәүдәгәре Исмәгыйль Апанай угылы дигән кешедән калган бер документның гыйбарәсен күчерә. Анда языла: «Тарих мең дә йите йөздә сиксән сикезенче йылда, йанварның сикезенче көнендә Казанның Иске Бистәнең йомышлы кеше мин, Йосыф Динмөхәммәд угылы саттым үземнең хассыма тигән колымны Казанның Иске Бистәнең Исмәгыйль Апанай хафиз угылына йөз сум хак берлә. Ошбу мәзкүр колларым Алат йулында, Арча округында Күшәр илендә йорт берлә торгучыдыр. Мәзкүр колларым: әүвәл – Бикбау Сәйдекәй угылы, хатыны Нәсиха, бер кызы сабый берлә угылы Бикчәнтәй Бикбай угылыны, икенче – колымның угылы Мортаза Мөэмин угылыны вә дәхи шул Күшәр илендә биләй торган йирләрем һәм печәнлегем – көллисе Исмәгыйль агайгадыр».

---

[1]Миңа быел җәй көне Спас кантоны Иске Рәҗәп авылында моннан алтмыш еллар алда Мәрҗанинең Рәҗәптә булганлыгын, анда кабер ташлары һәм кулъязмаларны тикшереп, язып йөргәнлеген, авыл картлары белән төрле мөсахәбәләр ясаганлыгын сөйләделәр. Мәрҗанинең Казан, Мамадыш, Лаеш, Зөя һәм Тәтеш өязләрендә булганы да мәгълүм. *(С.Вахиди иск.).*

*хасс - өлеш*
*мөсахәбә - әңгәмә*
*дәхи - тагын*
*көллисе - барчасы*

«Мөстәфадел-әхбар» шул ук җилдтә, 70 биттә Мамадыш кантоны Тенеки авылында моннан ике йөз еллар алда Әмкә мулла дигән кеше тарафыннан язылган кулъязма китаптан материаллар күчерә. «Мөстәфадел-әхбар» шул ук җилд, 78-89 битләрдә Идел буе Болгар галимнәре вә аларның әсәрләре турында язганда XII, XIII, XIV йөзләрдә булган кулъязма әсәрләрнең баш һәм ахыр якларыннан гыйбарәләр күчереп, алар турында изахлар яза[1] һәм үзенең сүзләренә бу кулъязмалардан алып, дәлилләр китерә.

«Мөстәфадел-әхбар» 2 җилд 8 биттә Спас өязе Иске Рәҗәп авылы имамнарыннан мулла Зәйнелгабидин Габделкәрим угылы дигән кешенең тәрҗемәи хәленә теркәлгән документның тәрҗемәсеннән түбәндәге урынны күчерә. Бу документ Рәҗәп халкының игенлек, печәнлек һәм умарталарның чикләреннән башка, авылларның чикләреннән аерыр өчен хөкүмәт мөһере белән ныгытылган рәсми документ булган. Документына языла: «Тарих йите мең дә ике йөз өченче, дикәбрәнең унөченче көне илән указ. Олуг газыйм падишаһ хәзрәте, олуг кенәз Питыр Әләкчич барча олуг вә кечек, ак падишаһ, Русийә йортыны үзе тотгучы, үзе биләгүче указ куәте илән Казан өязенең Рәҗәп авылының татарлар йукарыда йазылган йирләр сукалатмак өчен һәм печәнен чапмак өчен указлар илән биләргә олуг падишаһ хәзрәтенең бердән йасак илән тармакга, йәгъни түләмәккә бер замандагы аңлатуны Казанга түләргә йаздым».

«Мөстәфадел-әхбар» 2 җилд, 9 биттә Олы Кавал имамы Сәлимҗан Дусмөхәмәд угылы дигән кешенең кулъязма бер китабыннан менә мондый тарихи бер парчаны күчерә: «Би-хисабе рус[2]. Йите меңдә ике йөздә сикез улган иде, бактылар

---

[1] Бу кулъязмаларның күбесе Мәрҗани көтепханәсендә булган. *(С.Вахиди иск.).*

[2] Моннан ике йөз егерме тугыз ел алда, әле урыслар һаман иске гасыр тарихы белән хисап алып баралар иде. Олы Кавал авылының Сәлимҗан Дусмөхәммәд угылының кулъязмасы язылган ел урыслар хисабынча 7208 булган. Бу ел милади белән 1700 ел булып, шуннан иске гасыр тарихының 5508 елы ташлана да 1701 дип санап кителә. Бу вакыйга заманында зур үзгәрешләрдән хисапланган. *(С.Вахиди иск.).*

*изах - аңлатма* *газыйм - бөек*

*би-хисабе рус - рус ел исәбе белән*

Гайсәнең тарихыны һәм мең дә йите йөздә булмыш. Ул Адәм галәйһиссәлам тарихыны ташладылар. Ошбу мең дә йите йөздән алдылар. Имди Гайсәнең тарихыны мең дә йите йөздә бер дип санай башладылар. Мең дә йите йөздә сикез улды пичин йылында, биш мең дә биш йөздә сикез йылы тәмам ташланды. Дәхи белгел, әй, сахибе тәмәййез, сале шәмсиййәнең өч төрле хисабы вардыр: беренә «фарсийә хисабы» диерләр, аның берлә әһле Болгар гамәл тотмыштыр; вә беренә «румиййә хисабы» диерләр, әһле нәсари гамәл тотмыштыр. Бәс, мәгълүм вә мәшруг булды, хәмәл хисабын җәмигъ мөэмин вә мөселманнарга белмәк ляземдер... Вә дәхи мәгълүм ула ки, ул фарсийә нәүрүзе улыр, ун көннән соң румийиә нәүрүзе улыр. Аннан ун көннән соң хәмәл нәүрүзе булыр, нитәк кем, шәһре Болгар голәмасы ишарәт кыйлдылар «бала нәүрүз», «карт нәүрүз» вә «сислек нәүрүз» дәйү вә һәрбер нәүрүз - берәр гоҗуз хисабыдыр».

«Мөстәфадел-әхбар» 2 җилд, 127 биттә Ташкичү авылында моннан бер йөз туксан ике ел алдан язылган бер китапның Ташкичү урманында яшеренеп язылуы турындагы мәгълүматлары, шулай ук «Мөстәфадел-әхбар»ның Идел буе болгарлары турында язылган битләрендә шәһре Болгардагы Олы манараның егылуы турында Спас өязе, Олы Чаллы авылының крәстиәне Фазлулла Бохарай угылы тарафыннан язылган «мәҗмәгъ»не эзләп табып, мәзкүр манараның егылу тарихын билгеләве һәм бу мәсьәләдә Ибраһим әфәнде дигән кешенең «мәҗмәг»ыннән күчереп әлеге манараның 1136 нчы һиҗри[1] елның җәендә сәламәт булучылыгы вә ул манара

---

[1]1136 һиҗри ел – 1724 миладида елга туры килә. *(Р.М. иск.)*

*пичин - маймыл*
*дәхи - тагын*
*сахибе тәмәййез - аерып караучы*
*сале шәмсиййә - кояш ел*
*вардыр - бар*
*фарсиййә - фарсыча*
*румиййә - грекча, византиячә*
*әһле нәсари - христианнар*
*мәшругъ - шәригать рөхсәт иткән*
*хәмәл - йолдызнамә буенча кучкар елы*
*җәмигъ - барлык*
*улыр - булыр*
*нәүрүз - яңа ел башы*
*нитәк кем - ничек, ни рәвешле*
*голәма - галимнәр, укымышлылар*
*гоҗуз - ?*
*мәҗмәгъ - җыентык*
*дарелфөнун - университет*

турында байтак тәфсыйлләтләрне язуы – боларның барысы да Мәрҗанинең документ һәм кульъязмаларны эзләгәнлеген, җыйганлыгын, алардан файдаланганлыгын күрсәтәдер.

Мәрҗани бу мәсьәлә турында байтак кешеләргә хатлар да язган. Безнең өчен гыйльми вә тарихи әһәмиятле булган бер хатыннан кайбер урыннарын күчерәбез. Мәрҗани моннан алтмыш дүрт еллар алда, үзенең шәкерте Хөсәен Фәезхановның вафатына тәәссеф итеп (Фәезханов Петербург (Ленинград) дарелфөнүненең Шәрык телләре бүлегендә лектор булып торганда 1866 ел июль 30 ында вафат) Газизулла һәм Кәлимулла дигән кешеләргә, 1283 һиҗри[1] елда язган хатында болай яза: «Мескенем мелла Хөсәен... вафат булган икән, ләбаса, ни кылмак кирәк... күп-күп хезмәтләр кылып, бинигһайә файдалар тигергән иде... Аның һәр төрле мәҗмугаләре вә китаплары булса кирәк иде. Безгә кул китаплары булганда, сатмакны ихтыяр кылсалар, без бәлки алыр ирдек. Хосусан, әййамен-нас вә тәварих вә әхвале галәмгә тәгальлекъле мәҗамигъ булса, безгә зарур ирде. Аның мәдрәсә хосусында тәхрир кылган бер рисалә мөсвәддәсе бар иде. Аны бәйаз кылып бастырмак ирадәсендә иде. Бичара, бәйазга форсаты булмагандыр. Шул рисалә җуялмаса икән. Мин аны бәйазга чыгарып бастырмак садрендә булыр идем. Ля әкалле тәгаддөде нөсух (нөсхәләрен арттыру) булырлык биш-алты нөсхә яздырыр ирдем. Бичараның сәгый вә иҗтиһады заигъ булмаса икән, ул бик яхшы, бик мөфид нәрсә иде... Хасыйле кәлям,

---

[1] 1283 һиҗри ел – 1866 милади елга туры килә. *(Р.М. иск.)*

*кул китаплар - яраклы, файдалы китаплар*
*әййамен-нас - гореф-гадәт, этнография*
*тәварих - тарихлар*
*әхвале галәм - дөнья хәлләре, тарихы*
*мәҗамигъ - җыентыклар*
*тәхрир кылу - язу*
*бәйаз кылып - акка күчереп*
*ирадә - теләк*
*садрендә - шәрәфле урын*
*ля әкалле - һич булмаса*
*хасыйле кәлям - сүзнең кыскасы*
*фиһрис - исемлек*
*матбуг - басылган*
*сәгый вә иҗтиһад - тырышлык*
*мөфид - файдалы*
*заигъ - әрәм*
*тәгальлекъле - бәйле*
*мөтәгальликъ - бәйләнешле*
*җөзъи - аерым*
*тәхрир - язма*
*мокаддәм - элек*
*мәзмүн - эчтәлек*
*ифадә - аңлату*
*истифадә итү - файдалану*

мөмкин булса, тизлек илән мәрхүмнән калган китапларны, исемнәрене язып алып, тәфсыйлән фиһрис ясап, мөмкин булса, баягы рисаләсе, шуңар мөтәгальликъ җөзъи кәгазьләрдә булган тәхрирләрене һәм безгә йибәрәсез. Мокаддәмдәрәк үзенең җәмегъ кылган бер мәҗмәгы булса кирәк иде. Болгар вә Казан хакында мәкаләсе булса кирәк иде. Безнең хатымызның һәм мәзмунене хат белән җәмәгатенә ифадә итәсез».

Мәрҗани «Галәләтез-заман фи тарихе Болгар вә Казан» исемле әсәрендә бу китапны һәр төрле мәҗмәгъ вә мәҗмугадән, шулай ук бу йирнең халкы тарафыннан язылган төрле язмалардан җыйнап тәэлиф иткәнлеген яза.

Югарыда язылган материаллардан ачык күренә ки, Мәрҗани һәр төрле иске кульъязмалар, документлар, мәҗмугаләр вә башка тарихи әсәрләрне тикшерергә, җыярга, алардан истифадә итәргә соң дәрәҗәдә әһәмият биргән. Боларның өстенә Мәрҗанинең үз гомерендә утыз биштән артык мөһим әсәрләр язганлыгын игътибарга алсак, үзе язган әсәрләренең матбуг булганнарының үзендә калган кульъязмалары, матбуг булмаган әсәрләренең оригиналлары һәм читтән җибәрелгән төрле кешеләр тарафыннан язылган шәһәр вә авыллар турындагы тарихларның кульъязмалары – менә болар үзләре генә дә Мәрҗани көтепханәсенә галимнәрнең дикъкатьләрен җәлеп итүдә зур гамил була алалар. Шуларга таянып без әйтәбез, Мәрҗани көтепханәсе, шөбһәсез, бик зур, бик бай көтепханә булган. Анда әллә ничаклы, хәзерендә бөтенләй табылмый торган кульъязма төп нөсхәләр, документлар, шәҗәрәләр, юридический памятниклар, авыллардан җыелган яки алардан күчереп алынган нөсхәләр бик күп булганнар. Мәсәлән, Бохарада укыган чакларында Мәрҗани Ибне Фөзланның Болгарга килгән вакытында язган сәяхәтнамәсенең бер нөсхәсен интихаб белән күчереп алган булган. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар»да язуына караганда, Мәрҗани күргән Ибне Фөзлан әсәренең нөсхәсендә Якут әл-Хәмәви һәм

башкалар күчергән сүзләрдән артык сүзләр анда бик күп булган.

«Мөстәфадел-әхбар»да язылуына караганда, Мәрҗани көтепханәсендә Идел буе Болгар галиме Ибраһим бине Хәзәр әл-Болгариның 751 һиҗридә[1] язылган «Китабе ысулел-Хисами» исемле әсәренең төп нөсхәсе һәм икенче бер Болгар галиме Сәдер бине Галәведдин әл-Болгариның шәкерте Ибраһим бине Мөхәммәд хуҗа Карәтмәни[2] дигән галимнең шул «Имам Фәхрелислам» исемле, һиҗрәттән 765 нче елда[3] язылган әсәренең һәм бер нөсхәсе аның кулында булган. Шулай ук «Мөстәфадел-әхбар»да язылуына караганда, Ибне әл-Әсирнең «Мәгърифәтес-сахабә» исемле әсәренең бик иске нөсхәсе Мәрҗани көтепханәсендә булган. Бу нөсхәне Мәрҗани Ибне әл-Әсирнең үз гасырына бик якын заманда булучылыгын яза. Боларга башка Мәрҗани көтепханәсендә аның хакында тикшеренү дәвам итә торган «Нәһҗел-фәрадис» нөсхәсенең бик иске вә бик мөһим кульязмасы булганлыгы һәм Хөсәен Фәезхановның байтак әсәрләре, бигрәк тә мәдрәсәләрне ислах турындагы әсәренең әле 15 нче елга[4] кадәр Мәрҗани көтепханәсендә сакланган булучылыгы - менә боларның барысы да Мәрҗани көтепханәсенең гыйлем ияләре өчен ничаклы әһәмиятле бер көтепханә икәнлеген күрсәтүдә көчле дәлил була алганлыкларын тәкрәр итәбез.

Мәрҗани үзе сәламәт вакытта үзенең милкендә булган китапларның кадерен белгән һәм аларның югалмау, таралмаулары турында тәдбир дә кылган. Хәтта ул үзе үлгәннең соңында да көтепханәсендәге китапларның таралмыйча саклану чараларын күрергә тырышкан. Без моны Мәрҗанинең үз кулы белән язып, үзенең һәм шаһитларның имзалары вә үзенең мөһере белән расланган васыятьнамәсеннән аңлыйбыз. Мәрҗани 1297 һиҗри, шәгъбан

[1] һиҗри 751 ел – милади 1350 елга туры килә. (*Р.М. иск.*)
[2] Карәтмән авылы бүгендә дә Казаннан ерак түгел бер татар авылы. *(С.Вахиди иск.)*.
[3] һиҗри 765 ел милади 1364 елга туры килә. (*Р.М. иск.*)
[4] 1915 ел күздә тотыла. (*Р.М. иск.*)

аенда[1] язган васыятьнамәсендә бу турыда менә болай яза: «Вә дәхи кәнди милкем улгучы җәмигъ китапларымны үз әүладымама вәкыйф иттем. Карнән бәгъдә карнь бер дә сатылмас. Истигъмаль кылып файдаланудан башка урында истигъмаль кылынмас. Файдалана торган ышанычлы кешегә дөрест васика берлә аз заманга гарийә биреп торырлар. Мәгазе Аллаһы, кәнди әүладым киселсә, туганнарыма вә әүладларына шул тарика вәкыйф улыр. Бу китапларның һәркаюсына исемем илә мөнәкъкаш «Вәкыйфы әүлад» дәйү яздырган мөһерем басылыр[2] вә тәфсыйлән дәфтәрдә исемнәре илә языльып, рәкымнәр илә мәркум кылыныр»[3].

Васыятьнамәдән аңлашылуына караганда, Мәрҗани көтепханәсе гасырлар буе таратылмыйча сакланырга тиеш булган. Көтепханәдәге әсәрләр белән вакытлы файдаланырга теләгән ышанычлы кешеләргә кулларыннан кәгазь алып, бераз заманга биреп торырга рөхсәт ителгән. Ләкин көтепханәдәге китапларның һәркаюсында «Балаларга вәкыйф» дип язылган мөһер басылган булырга тиеш булган.

Мәрҗани көтепханәсенә хәзерге вакытта баш хуҗа – аның угылы Борһан хәзрәтнең хатыны Маһисәрвәр абыстай Мәрҗания һәм аның балаларыдыр. Алар әле дә шул ук Мәрҗани торган өйдә торалар, Мәрҗанинең көтепханәсе дә алар белән бергә, шул ук йортта саклана. Мәрҗанинең васыяте варислар тарафыннан эшкә ашырылгандырмы яки юктырмы

---

[1] 1297 һиҗри елның шәгъбан ае милади 1880 елның июль аена туры килә. *(Р.М. иск.)*
*интихаб белән - сайлап, сайланма рәвештә*
*тәдбир - чара*
*кәнди - үз*
*җәмигъ - барлык*
[2] Шундый эчтәлектәге мөһер сугылган китапларның берсе (Тәрҗемәи борһане катыйг. - Каһирә, 1870) Нажия Ильясовада сакланган. *(Р.М. иск.)*
[3] «Мәрҗани» мәҗмугасе. 135-136 битләрдә. *(С.Вахиди иск.)*.
*тарика - юл белән*
*әүлад - балалар*
*карнән бәгъдә карнь - гасырдан-гасырга*
*истигъмаль кылу - файдалану, куллану*
*васика - язма документ*
*гарийә - бурыч*
*мөнәкъкаш - бизәлгән*
*дәйү - дип*
*рәкым - сан, номер*
*мәркум - номерланган*
*һәйәте тәхририя - редколлегия*

– ул мәсьәлә, әлбәттә, безгә караңгы, аны тикшерү безнең эшебез дә түгел.

Моннан берничә еллар алда ук мин Мәрҗани көтепханәсенә кереп, андагы әсәрләр белән танышырга, алардан файдаланырга теләгән идем. Мәрҗанинең васыяте буенча көтепханәгә кертерләр дип уйлаган идем. Ләкин эш мин уйлаганның киресенчә булды. Мәрҗани көтепханәсеннән файдаланыр өчен аның соңгы хуҗаларыннан рөхсәт алу мөмкин булмады. Мәрҗанинең варислары, бигрәк тә Борһан хәзрәтнең хатыны Маһисәрвәр абыстай, көтепханәнең иң әһәмиятле өлешен сандыкларга тутырып кладовойда асрау, мөмкин кадәр андый әсәрләрне үзенә якын торган берничә кешеләрдән башкаларга күрсәтмәү юлы белән саклау тактикасын алып барган. Мәрҗани мәҗмугасендә язылуына караганда, Мәрҗанинең тууына йөз ел тулу мөнәсәбәте белән мәзкүр мәҗмугане язучы һәйәте тәхририя әгъзаларына да көтепханәнең бөтен өлеше белән файдаланырга рөхсәт ителмәгән. Аларга да Борһан хәзрәттән калган шкафларда булган китапларны каратудан ерак җибәрелмәгән.

Хәзерге вакытта Мәрҗани көтепханәсенең баш хуҗасы булган Борһан хәзрәт хатыны Маһисәрвәр абыстай аңардан шул турыда мәгълүмат алырга җибәргән минем кешемә түбәндә язылачак сүзләрне сөйләгән. Аның сүзләрен үзеннән ишеткәнчә, үзгәртмичә, без монда язып китәбез. Ул әйтә: «1917 елны безгә хәбәр бирәләр: Мәрҗани хәзрәтнең көтепханәсен университеткә алалар икән. Бүген мәсҗед очырмасындагы китапларны карыйлар, иртәгә сезгә керәләр дип. Шуны ишеткәч мәрхүм угылым Габделхәмид хәзрәт «Әни, без бу китапларны яшеребрәк куйыйк» диде дә, шул көнне очырмага биш сандык китап ташып куйдык. Ул китаплар очырмада шулай тордылар. Ике-өч ел үткәч бездә пожар булып, очырмабыз янды, шунда бу китаплар да яндылар. Янып бетми калган кисәкләрен, урталарын яндырсак, гөнаһ булмас микән дип, Галия абыстайга (Мәрҗани кызы, Сафый мулла хатыны) киңәш иттем дә, аунап йөргәнче дип, яктык. Кайбер

калганнары, кырыйлары көйгәннәре әле дә очырмада ике капчык ята. Миннән «Нәһҗел-фәрадис» китабы сорап аптыраталар, бик кыйммәт бәһагә алабыз дип әйтәләр; хөкүмәт кешеләре дә сорадылар, ләкин ул китап хәзер бездә юк. Каядыр, кая киткәнен дә белмибез. Хәзер инде хәзрәтнең (Мәрҗани) күп китаплары бетте, без инде аларны яхшы саклый белмәдек шул» ди абыстай.

Мәрҗани варисларының кайберләре белән мин үзем бу турыда мөсахәбәләр ясадым. Аларның Мәрҗани көтепханәсе турында сөйләгән сүзләре менә шуннан гыйбарәт: «Көтепханәгә моңа кадәр байтак кешеләр кереп-чыгып йөрделәр. Үткән ел бер мулла көтепханәне тикшереп карап чыкты. Аннан соң Әфтах мулла Тәрҗемани көтепханәдәге барлык китапларның исемлеген язды. Ул исемлек әле дә Әфтах мулла кулында, Яңа Бистәдә ди.

Дәвамында безнең китаплар әкренләп югалдылар шул инде, вакытлы файдаланырга алган кешеләр китапларны яңадан кайтармадылар. 1920 нче елда булган ут казасыннан очырмага куйган биш сандык китаплар янып юкка чыктылар» диләр.

Әгәр дә аларның Мәрҗани көтепханәсе турында сөйләгән сүзләре барысы да дөрес булса, Татарстан Җөмһүриятенең мәркәзе булган Казан шәһәрендә бик зур гыйльми дәүләт юкка чыккан була. Шөбһәсез, моңар бик тирән аяныч вә тәәссеф белән карарга туры килә.

Мәрҗани көтепханәсенең соңгы кызганыч тәкъдире белән XIV нче йөзнең соңгы яртысында борынгы татар әдәби теленең ничек булганлыгын күрсәтә торган бердәнбер кульязма «Нәһҗел-фәрадис» нөсхәсенең тәкъдире дә шул ук варисларның сөйләвенә караганда, һичбер кыйммәтле булмаган бер рисалә шикелле юкка чыгарылган була.

Мәрҗани көтепханәсе, аның башлап төзелеше, анда булган һәр төрле әсәрләр, ниһаять көтепханәнең бу көндә гомумхалык өчен файдаланырга мөмкин булып яки булмавы мәсьәләләре – менә болар, шөбһәсез, әһәмиятле булган, хәзерге вакытта

чишелергә тиешле мәсьәләләрдән булганга күрә без, гәрчә бу хезмәтебезне рус телендә чыга торган гыйльми журналларның берендә бастырырга хәзерләп куйган булсак та, менә боларны мөләхазә итеп, татарчада нәшер итәргә уйладык. Шуны да әйтеп китәргә тиеш ки, безнең бу тикшеренүләребез бәлки тулы тикшеренү вазыйфасын үти дә алмас. Һәрхәлдә, киләчәктә бу мәүзугта казынучы егетләргә безнең бу хезмәтебез материал була алса, без вазыйфабызны үтәгән булабыз.

Мәрҗани көтепханәсенең әүвәлдә каталогы яки инвентарь журналы булганмы-юкмы яки алар көтепханәдән югалтылган бик күп әсәрләр шикелле соңыннан югалганнармы – без әлегә ул турыда һичбер төрле мәгълүмат ала алмадык.

Соңгы сүз итеп шуны әйтергә тиеш ки, гәрчә Мәрҗани көтепханәсеннән бик күп әсәрләр югалган һәм янып юкка чыккан булсалар да, шөбһәсез, әле анда сәламәт сакланып калганнары да байтак булырга тиеш. Һәрхәлдә, көтепханәгә кереп, җитди тикшерүләр ясаганда, әһәмиятле кульязма, аерым кәгазь һәм документларның табылачагына мин ышанып карыймын.

*(«Безнең юл». - 1929. - № 6/7. - Б. 14-17.)*

---

*мөләхазә - фикерләү, уйлау*
*мәүзуг - мәсьәлә, юнәлеш*



«Мәрҗани хәзрәтләренең әсами көтебе» каталогы.
*Татарстан Милли китапханәсенең*
*Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 953 т.*


خاتمه تحفه اثنا عشری ۶۳۸

ومتکلم اجل تازه کننده علم قدما رونق ده کلام ادبا محقق فروع واصول مدقق معقول و
منقول کامل التمیز شاه عبد العزیز صاحب دهلوی قدس الله سره العزیز بتصحیح فاضل لوذعی
عالم لمیعی عمی ومعظمی ذو الفضل والامتنان جناب مولوی محمد احسان الله صاحب لکنوی
انصاری سلمه الله الباری عن شر کل غبی وغوی باختتام رسیده الحق کتابیست سالک
راه سنت را هادی کافی وطالب رشاد را رهبر وافی هر هر لفظش پر از معانی مفیده وانبهر هر
کلمه اش مطالب دقیقه چکیده دلائلش از تعسف وتعصب مبری مقدماتش از جدل ومحکم
معرب قیاساتش بشرائط صناعت مزین اقوال منقولاتش بتصحیح نقل محسن فی الواقع مکتوبیست
که دبیر فلک در تحریر جوابش ژولیده رقم وصحیفه الیست که عقل کل در تحریر پاسخش از عجز طبیعت
خود وقطعیه دلیلش کوتاه قلم نیر معانی در استتار الفاظش چون آفتاب در ابر باریک جلوه گر
وعروس مبانی در پرده بیان مستتر اختصارش بجامعیت مطالب از تطویل خوشتر وتطویلش
یاز دیاد مطالب از اختصار بهتر بهر اعتراضش جذر اصم وهر ادعایش مبرهن ومحکم لله در القائل
حیث قال ان سدها القاصرون فقبلها الماهرون فی الجمله کتابیست لاجواب بی عدیل وانتخاب
کرة بعد کرة مرة بعد مرة طبع گردیده واز قدردانی شائقین نسخه باقی نمانده مژده باد طالبین را
بازاین دریکتا وگوهر بی بها بارزانی فروخته میشود قیمت یوسف چند درهم چه گران ست اولتعالی
رونق این مطبع بتصحیح وکثرت انطباع بیفزاید وآخر دعوانا ان الحمد لله رب العالمین والصلوة والسلام
علی خیر خلقه محمد وآله وصحبه اجمعین

سنه ۱۳۰۲ هجری
ماه دسمبر سنه ۱۸۸۵ ع

ودشمنک قول الناس فیما ملکته ه لقد کان هذا مرة لفلان ه

وانا عبد الله الفقیر شهاب الدین بن بهاء الدین بن سبحان بن عبد
الغفور ... المرجانی سلمه الله تعالی

Ш.Мәрҗанинең автографы теркәлгән һәм мөһере сугылган
«Төхфәте исна гашәрә» (Һиндстан, 1885) исемле китап.
*Татарстан Милли китапханәсенең*
*Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: Т 1466108.*



Ш.Мәрҗанинең автографы теркәлгән һәм шушы китапның балаларына мирас итеп калдырылуын белдергән махсус мөһере сугылган «Тәрҗемәи борһане катыйг, 2 нче җилд» (Каһирә, 1870) исемле китап.
*Нажция Ильясованың шәхси архивы.*



Ш.Мәрҗанинең Коръән басмасындагы хаталарны
төзәтү-тикшерү эше язмасы.
*Татарстан Милли китапханәсенең*
*Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 966 т.*


( ٣٤٨ )

درة الفاخرة مختار كنز وقايه منار شرح مجمع شرعه وصايا اخلص الخالصه بداية الهداية
قنيه رسالة الشوقيه تاويلات قاشانى نقايه برازية قاضيخان جامع الفتاوى لمعه نورانيه
تفسير قاضى تفسير ابى الليث كشاف قصص الانبياء مثنوى انيس جليس
شرعه شرحى هدايه شرحى نصايح الاجناس مجالس واعظيه مشكوة
شامل انيس المنقطعين تفسير حنفى فتاوى صوفيه
نجاة الذاكرين محيط جلالين تفسير بغوى
رساله تحقيقيه تفسير شعبى درر
معانى مظهر شهاب اربعين
فرايض خمسين
[illegible] تفسير وجيز لباب [illegible]
عاشق پاشا كتاب احمدى
[illegible] فضائل رمضان ديوان چلپى [illegible]
منهاج العابدين كشف
[illegible] كفاية المجالس [illegible]
شمس المعارف

تم
بعون الله الملك
الوهاب

نبينا صلى الله
تعالى عليه وسلمك
هجرتيدن ١٣٠٠ نچى سنه
صفر الخير آينك يكرمى
توقزنده وكانون اولك يكرمى
جيديسنده دوشنبه كون
اشبو كتابك طبعينه
اتمام ميسر اولندى
الحمد لله رب
العالمين

نفعنا الله
به وجميع اخواننا
المؤمنين

Ш.Мәрҗанинең кызы Бибихауаның автографы теркәлгән
«Китабе гыймадел-ислам» (Казан, 1882) исемле китап.
*Татарстан Милли китапханәсенең*
*Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: Т 1466093.*



4

قزانده خانلق تأسیس قیلنغانی

قای وقتدن بیرو قزانده مستقل بالامر خانلار بولا باشلاغانی واول
خانلقنی کیم اول تأسیس قیلغان، بو خصوصده اعتمادغه لایق مسلمان
تاریخلرنده نقل صریح کورکانمز یوق ودهم خلق آوزنده سلفدن
خلف روایت ایتوب کیلکان خبرده ایشتکانمز یوق. بلی
رسالهٔ تواریخ بلغاریه صاحبی شرف الدین بن حسام الدین
قزانده اول خانلق ایتکان الهام خان بولوینه اشارت ایتادر اما
خانلق ایته باشلاوی قای یلده ایدی مونی ایتمای شرف الدین نینک
سوزینه خصوصا خلافنه روایت طابلغانده طایانوب بولمایدر
چونکه شول کتابی نینک بارسیدن آرتوق توسنده کورکان
اصلسز وخطا سوزلر بیلین طولودر. بلی قزان خانلاریدن
الهام خان بار اول اوکلی خان توکل اننک عصرینی صونکراق کیلودر
وبینه بو مختصر بلغار تاریخنی کورکانمز بار آنده تیمور بلغارنی
حراب ایتکانده بیکچوره خان خان ایدی واننک بر عالم بیک
دیکان اوغلی حراب بولغان بلغار یرینه قزان شهرین صالدی
دیو بوده زمانن یاد ایتمای وهم استقلالا خانلق ایتکانن ایتمای کرچه بو کتابده هم بیک کوب خطالر بار اما
بو سوزنی ~~طوب طوغری~~ خطا دیب ایتوب بولماس ~~چونکه کیلاچکده~~
~~ذکری کیلورکم روس تاریخلری نینک بعضیسنده محمودک قزاننی صوغشوب~~



Х. Фәезхановның «Казан ханлыгы» хезмәтенең кульязмасы.
*Татарстан Милли китапханәсенең*
*Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 1949 т.*


١٠

№ 8

تمام محو بولغان

بو طاش هم یول دن اونگ یاقده ماقبلنده کی طاش ایله بیاشه یازوواثرلری بار لیکن ~~هیچ بر حرف~~

هیچ او قوریغه ممکن توگل

№ 9

بو طاش هم یولدن اونگ یاقده بولغه یاقین لیبوکلا آرشین یاریم قدر بو طاش هم

یازولو بولمق کرک اصلا بر حرف ده بیلنمای در موشکا یاننده گیره ~~...~~ بش دانه گیراک

طاش لرننگ برنده یازوواثری بار

№ 10

~~ایکی طاشنی~~ بو طاش یولننگ صول یاننده یولغه یاقین ایکی طاشنی بر بری اوستنه

قویوب عادی آرشین یاریملی طاش ایتوب قویغانلار ایکی طاشده ۹ ویا شول غنه

اورناطاشلارننگ ایکی عالب اوچ چرک آرشین ... برآرشین ... با ... بوقاری قطعه سنده

یازوی بوقدر ~~اوولدی~~ دورت سطر بوقدر سوزلر او قلنه

الحکم لله

..... الکبیر

..... واد

ساک ب

توبانکی قطعه سنده ایکی سطر یازو بار ... دا ایلا او قوممکن ... قولدن طانی ... 

موننگ یاننده ینه بر کیچلنه طاش بار آنده الکبیر دیگان سوز !

Х. Фәезхановның ташъязма истәлекләр турындагы хезмәтенең кульязмасы.
*Татарстан Милли китапханәсенең Кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 1949 т.*


بسم الله الرحمن الرحیم

956 т.

Ш. Мәрҗанигә мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев язган хат.

*Татарстан Милли китапханәсенең*

*Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 956 т.*

# РЕЗЮМЕ

Научно-библиографический сборник «Библиотека Марджани» посвящен библиотеке известного татарского историка, богослова, философа и просветителя Шигабутдина Марджани (1818-1889). Он составлен и подготовлен к печати ведущим научным сотрудником Отдела рукописей и редких книг Национальной библиотеки Республики Татарстан, кандидатом филологических наук Р. Мардановым.

Вступительная статья посвящена судьбе библиотеки Марджани. Основу этой книжной коллекции составили его личные книги, приобретенные еще во время обучения в учебных заведениях Средней Азии, а также богатое собрание унаследованных от предков книг. В казанский период жизни Ш. Марджани, активно занимаясь наукой, периодически пополнял свою библиотеку древними и редкими рукописными книгами, печатными изданиями. В библиотеке ученого имелись рукописные и печатные книги на разных языках: татарском, арабском, персидском, турецком и др., относящиеся к периоду XII-XIX вв.

После смерти ученого, согласно завещанию, богатую библиотеку унаследовали его дети.Уже в начале XX века библиотека Марджани находилась в центре внимания татарской научной общественности. Долгое время считалось, что богатейшая библиотека погибла при пожаре в 1920 г. Об этом писали ученые Г. Губайдуллин, С. Вахиди, М.Усманов и др. Но факты свидетельствуют о том, что библиотека была уничтожена не полностью и часть коллекции сохранилась. Отдельные части этого уникального книжного собрания в настоящее время хранятся в фондах Научной библиотеки им. Н.И. Лобачевского Казанского государственного университета, в Архивохранилище Института языка , литературы и искусства Академии Наук Республики Татарстан, в музее Национально-культурного центра «Казань» и в Национальной библиотеке Республики Татарстан, а также у потомков Ш.Марджани и в других частных коллекциях.

В результате кропотливых научных изысканий Р. Марданова была обнаружена еще одна часть коллекции, которая ныне хранится в фонде Национальной библиотеки РТ. Среди бесценных находок имеются различные рукописи самого Ш.Марджани, исторические труды Хусаина Фаизханова (1828-1866), каталог библиотеки Марджани и др. материалы.

Публикуемый каталог (436 названий рукописных и печатных книг) библиотеки Марджани отражает лишь часть книжного собрания ученого.

В качестве приложения к сборнику представлены статьи Ш. Шарафа и С. Вахиди, посвященные библиотеке Ш. Марджани, а также иллюстративный материал.

## RESUME

The scientific and bibliographical collection titled «The Marjani's Library» is dedicated to the library of a well-known Tatar historian, theologian, philosopher and enlightener Shigaboutdin Marjani (1818-1889). It was compiled and prepared for publication by Candidate of Philology R. Mardanov, a leading research assistant of the department for manuscripts and rare books of the National Library of the Republic of Tatarstan.

The introductory article is dedicated to the fate of the Marjani's library. The backbone of this collection of books was formed by his personal books acquired yet at the time of studying at educational institutions of the Middle Asia, and by the rich collection of books he inherited from his ancestors. During the Kazan period of his life, Shigaboutdin Marjani was actively engaged in research activity and periodically replenished his collection by ancient and rare manuscripts and prints. His library contained manuscripts and prints in different languages: Tatar, Arabic, Persian, Turkish, etc. dating back to the 12th – 19th centuries.

According to Marjani's will, his rich library was inherited by his children. Already in the early 20th century the Marjani's library was in a focus of attention of the Tatar scientific community. It was long believed that the library was lost in the fire in 1920, of which one can read from works by such scientists as G. Goubaidoullin, S. Vakhidi, M. Usmanov, etc. But the facts testify that the library was lost only partially, and its certain portion survived. Some separate parts of this unique collection of books are kept nowadays in the stocks of the Lobachevsky Scientific Library of Kazan State University, at the Archives of the Institute for Language, Literature and Art of the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, at the museum of «Kazan» Centre for National Culture, at the National Library of the Republic of Tatarstan. Some parts of it are also kept by descendants of Shigaboutdin Marjani and in other private collections.

A new portion of the collection was found owing to laborious scientific research conducted by R. Mardanov and is kept today in the stocks of the National Library of the Republic of Tatarstan. Among the invaluable finds there are different manuscripts of Marjani himself, historical works by Khusain Faizkhanov (1828-1866), a catalogue of the Marjani's library, and other materials.

The catalogue of the Marjani's library reflects only a part of his collection of books. Here we publish a complete list containing 436 titles of manuscripts and prints.

To this collection we also added an appendix containing the articles by Sh. Sharaf and S. Vakhidi dedicated to the Marjani's library, as well as some illustrative materials.

# ЭЧТӘЛЕК

Мәрданов Раиф. Шиһабеддин Мәрҗанинең шәхси китапханәсе......3

МӘРҖАНИ КИТАПХАНӘСЕНЕҢ ИСЕМЛЕК-КАТАЛОГЫ

Кульъязма китаплар ......22
Басма китаплар ......43
Сүзлек......92

КУШЫМТА

Шәһәр Шәрәф. Мәрҗани китапханәсе турында......94
Сәет Вахиди. Мәрҗани көтепханәсе һәм аның соңгы язмышы......100

Резюме......120
Resume......121

Библиотека Марджани:
научно-библиографический сборник

*(на татарском языке)*

Составитель: Р.Ф. Марданов
Компьютерная верстка: Л.М. Клюге
Компьютерный набор: О.В. Фофанова, Н.К. Гарипов

Басарга кул куелды 25.02.04. Форматы 60x84/16.
Тиражы 500 данә. Заказ № 174.
Татарстан Республикасы Милли китапханәсе.
«Милли китап» нәшрияты.
420111, Казан шәһәре, Кремль ур., 33
Подписана к печати 25.02.04. Формат 60x84/16.
Тираж 500 экз. Заказ № 174.
Национальная библиотека Республики Татарстан.
Издательство «Милли китап».
420111, г. Казань, ул. Кремлевская, 33.

Отпечатана в секторе множительной техники редакционно-издательского отдела Национальной библиотеки Республики Татарстан.
420111 г. Казань, ул. Кремлевская, 33